www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 4 (1369) 4 февраль 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga

8

Композитор, дирижер Ильяс Камал татар музыкасын дөньяда танытырга, бу юнәлештә пропаганданы арттырырга кирәк, дип саный.

12

Тамашачы күңеленә берсеннән-берсе үзенчәлекле рольләр белән мәңгелеккә кереп калган Ирек Баһмановка туксан яшь тулган булыр иде...

24

Мәскәү рәссамы Рената Абдуллина күңелендә туган матур, жете төсле сурәтләрне табигый ефәк тукымаларга төшерә.

Риваятьләр кылу маһирлеген Сәнгать иткән безнең бабайлар!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Башкортстан Бөтендөнья башкорт корылтае бу елны Башкорт мәдәнияте һәм рухи мирас елы дип игълан итте.
- Таллин шәһәрендәге Эстон теле йортында Нарвадагы татар җәмгыяте оештырган «Европа Сабан туе» фотокүргәзмәсе ачылды.
- ЮНЕСКОның Париждагы штаб-фатирына Казан обсерваторияләрен Бөтендөнья мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү мөрәҗәгатенә бәйле биш томлык документлар тапшырылды.
- Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында бирелгән грант нигезендә Минзәлә шәһәренең «Таңкай» балалар бакчасында балалар мультстудиясе ачылды.
- «Литературные знакомства» әдәби альманахының 2021 елгы соңгы саны татар язучылары әсәрләреннән төзелгән.
- Мәскәү шәһәрендә узган «Роза ветров» халыкара иҗат һөнәри һәм һәвәскәр шөгыльләнүче балалар һәм яшүсмерләр бәйгесенең Бөтендөнья финалында Бөгелмәнең «Мәскәү вакыты» бию коллективы Гран-прига ия булды.
- Рус биографика институты милләттәшебез, «Ямалдорстрой» компаниясе президенты һәм хәйрияче Марс Гайнетдиновны «Ел кешесе-2021» дип билгеләгән.
- Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә XX татар хор музыкасы фестивале ачылды.
- Башкортстан әдибе Флүр Галимовның «Азгын тәүбәсе» дип аталган трилогиясе Төркия нәшриятында аерым китап булып дөнья күрде.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Камил ИСХАКОВ, Татарстан Президенты ярдәмчесе, Казан шәһәренең экс-мэры:

«Көнкүрештә кулланыла торган татар сөйләм телен өйрәтмичә, синтаксис, морфология өйрәтергә нигә кирәк иде?! Телгә мәхәббәт түгел, ә нәфрәт уята ул. Әле аны тормышта кулланмыйсың да бит. Менә шулай үз кулларыбыз белән республикада татар телен үтердек».

СЫНАМЫШЛАР

10 февральдә җилле булса, ел яңгырлы була ● Февраль карга бай, апрель суга бай ● Февральдә каен ботагында кар алка-алка булып асылынып торса, ул елны иген уңар ● Томан югарыда торса – көн аязы, аска төшсә – җепшек кар ява.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 31 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 23 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **8 сәгать 52 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **29 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **11 февральдә 9 сәгать 21 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

4 февраль – язучы, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ибраһим Зарифулла улы Газинең (Мингазиев) тууына 115 ел (1907–1971).

5 февраль – язучы һәм шагыйрь Нәби Зарип улы Зариповның тууына 105 ел (1917–2003).

7 февраль – Татарстан Республикасының Югары Советы тарафыннан Татарстанның Дәүләт гербы кабул ителүгә 30 ел (1992);

– сәнгать белгече, рәссам, педагог Рәмзия Идиятулла кызы Такташка 90 яшь (1932).

8 февраль – театр белгече, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Илтани Исхак кызы Иляловага 90 яшь (1932).

10 февраль – балет биючесе, балетмейстер, Россиянең халык артисты Шамил Хәйрулла улы Яһүдиннең тууына 90 ел (1932–2005).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Февральнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 4 февраль.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(1-8 февраль)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **16 гыйнвардан 17 февральгә кадәр** ашказаны, ашказаны асты бизе, талак актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген рәҗәб аеның 3 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ

Яхшырак яшәргә өметләнәбез



Җитәкчеләр гадәттә һәр чыгышларында халыкның тормыш хәле турында сөйләргә ярата. Янәсе, алар һәр гамәлләрен шушы максаттан чыгып эшли. Әлбәттә, түрәләр үзләре яхшы яши. Аларның күпчелегенең хатыннары да, бала-чагалары да миллионер. Түрәләр хезмәт хакларыннан тыш керемнәрен шуларга күчереп бара.

Халыкның пенсиягә чыгу вакытын биш елга чигерү дә зур ризасызлык тудырды. Болай да бик күпләр пенсиягә чыгу вакытын түземсезлек белән көтә иде бит. Бездә кешенең гомер озынлыгы күп кенә илләр белән чагыштырганда шактый кыска булуга да сер түгел. Пенсиягә чыгуга үлеп китүчеләр азмыни?

Социаль мәсьәләләр буенча вице-премьер Татьяна Голикованың әйтүенә караганда, пенсиягә чыгуның яңа системасына кагылышлы закон проекты Дәүләт Думасының һәм хөкүмәтнең уртак позициясе. Ул озак еллар буе тикшерелгән. Аны гамәлгә кертү өчен моңарчы икътисади һәм социаль җирлек булмаган. Үткән гасырның җитмешенче елларында Россиядә бер пенсионерга 3,7 эшләүче туры килсә, хәзер ул 1,2 генә икән. Янәсе, бу эшләүчеләр генә пенсионерларны туендырып тора алмый.

Татьяна Голикованың "Ломать пенсионную систему не будем, только модернизируем", - дигән сүзләре дә гаҗәпсенү тудыра. Биш елга озайтылган системаны бары тик "модернизацияләнгән", дип булмый бит.

Дөрес, вице-премьер хөкүмәтнең кешеләрне тормыш алып бару өчен пенсия белән тәэмин итә алачагына үзе дә ышанып бетми. Пенсияләрне зур күләмдә билгеләү өчен дәүләтнең ресурслары юк дип саный. Монда инде дөрес инфраструктура булдыру зарур. Шунлыктан һәркем, эшләгән вакытта ук булачак пенсиясенә өстәмә туплап барса отачак. Пенсиягә чыккач, ул иркенрәк яши алачак. Пенсиягә өстәмә туплау иреккле. Кешене моңа мәҗбүр итә торган закон юк.

Рәсми мәгълүматларга караганда, бүген 15 миллион кеше иминият взносы түләми. Бик зур сумма бу. Әгәр ул түләнсә, пенсия фонды кытлык проблемасын каплатып та булыр иде. Һәркемгә аңлашыла, бу катлаулы бурыч. Пенсия фонды, федераль салым хезмәте, мәҗбүри медицина страхование фонды белән берлектә хөкүмәт мондый кешеләрен исәпкә алу буенча карарлар кабул итте. Рәсми төстә эшләми дип саналучы, иминият взнослары түләмәүче затларга бушлай дәүләт ярдәме, шул исәптән медицина хезмәтләре күрсәтергәме дигән бәхәс бара. Җитәкчеләрнең кайберләре, әгәр кеше конституция принципларын боза, хезмәт хакын пакет белән ала, салымнар түләми икән, үзләре дә дәүләттән бернәрсә дә, шул исәптән пенсия дә, медицина ярдәме дә алмаска тиеш дигән фикердә. Әмма Россиянең андый законы юк. Россия – социаль дәүләт. Шунлыктан илдә яшәүче һәркем турында кайгыртыла, аларга да мөмкин кадәр ярдәм күрсәтелә.

Безнең җәмгыять өчен гаделлек бик мөһим. Бу хакта һәркем уйланырлык шартлар тудыру зарур. Салым системасы да һәркемне кызыктырырлык булсын. Берәү дә үзенә картлык киләчәген дә онытмасын. Билгеле инде, хезмәт хакларын конверт белән алып йөрүчеләрнең пенсияләре зур булмый. Күбесе минималь пенсия генә ала. Кайбер хезмәткәрләр эш бирүчеләр белән бәхәсләшә дә алмый шул. Әгәр алар үзләренең хокукларын аңлата башласа, бөтенләй эшсез кала. Ә һәркемгә яшәргә дә, ашарга да кирәк.

Рәсми мәгълүматларга караганда Россиядә 146,9 миллион кеше яши. Аларның 46,5 миллионы, ягъни 31,7 проценты пенсионер. Пенсионерларның 26,4 проценты (12,3 миллион кеше) эшчәнлеген дәвам итә.

Тикшеренү үзәкләренең берсе үткәргән сораштырулардан күренгәнчә, хатын-кызлар – 53, ә ирләр 55 яшьтән пенсиягә чыгарга тели. Лаеклы ялга чыгарга аеруча дизайнерлар, маркетологлар, юристлар һәм бухгалтерлар ашыга. Ә программист хатын-кызлар һәм персонал белән эшләүче ирләр пенсиягә соңрак чыгарга да риза икән. Сүз уңаеннан: Татарстанда рәсми теркәлгән 17 мең чамасы эшсез исәпләнә.

Сер түгел, кешеләргә илле яшькә җиткәндә эш табу авыр. Андый яшьтә инде кешенең энергиясе кими, ешрак авырый. Бу мәсьәлә хакимиятне дә борчый. Шуңа күрә чаралар комплексы эшләнә. Аның төп максаты – эштән бушатылган кешеләрне ташландык хәлдә калдырмау. Аларның квалификацияләрен күтәрү, яңа һөнәрләргә өйрәтү күздә тотыла. Хәер, мондый чара өлкәннәргә генә түгел, яшьләргә дә кагыла. Мәшгульлек оешмалары эш бирүчеләр белән активрак эшләргә тиеш.

Гадәттә хезмәт биржаларында минималь хезмәт хакы яки түбән квалификацияле эш урыннары тәкъдим итәләр. Зур тәҗрибәсе булган кеше, билгеле инде, моңа риза булмый. Андый кешеләр өчен бәлки вакытлыча эшсезлек пособиесен арттыра төшәргә кирәктер. Дөрес, хәзер минималь һәм максималь пособиеләр турында закон проектлары әзерләнә. Максималь пособие яшәү минимумы чыгымнары белән тигезләшергә тиеш. Өлкәнрәк яшьтәге кешеләр авыр хәлдә калган очракларда да пособие алачак. Хәзергә Россиянең күпчелек төбәкләрендә яшәү минимумы 11 мең сум дип санала. Әлбәттә, мондый суммага яшәү бик авыр. Аның шактый өлеше фатирга түләүгә китеп бара.

Минималь хезмәт хакы алып яшәүчеләрнең дә хәле авыр. Алардан салым тотмаска дигән тәкъдимнәр дә булды. Ә бюджет керемнәрен киметмәү өчен байларга салымны арттыра төшәргә киңәш иттеләр. Әмма хөкүмәт моның белән килешмәде. Дәүләт Думасы да андый закон кабул итмәде. Күрәсең, хөкүмәт аппаратында эшләүчеләр дә, нигездә байлардан торган парламент депутатлары да керемнәрен киметергә теләмәде. Нәтиҗәдә, гадел карар кабул итүгә сәләтсез булуларын күрсәттеләр. Югыйсә, аларның хезмәт хакларының бик югары булуы, пенсиягә дә дәүләт хезмәткәре статусына ия затларның башкалардан берничә тапкыр артык алуы һәркемгә мәгълүм бит. Гадәттә, һәр чыгышларында гаделлек турында сөйләргә яратучылар гаделлек белән тәңгәл килә алмады. Түрәләрнең беренче чиратта үз мәнфәгатьләрен кайгыртуы сер түгел шул. Шуңа күрә депутат булырга теләүчеләрнең чамадан тыш күп булуы һәр сайлау алдыннан ачык күрәбез. Бөтен ил язмышы ышанып тапшырылган президент та бу мәсьәләне хәл итүне көн тәртибенә куймый. Монда да уйлану өчен җирлек бар.

Дөрес, еллар буе халыкны борчыган проблемаларның кайберләре авырлык белән булса да хәл ителә. Әле кайчан гына күпчелек гаиләләр балаларын бакчаларга урнаштыра алмый интекте. Хәзер Россиянең күпчелек төбәкләре буенча да, шул исәптән республикада да мондый проблема калмады. Кирәк кадәр балалар бакчалары төзелде, җиһазлар алынды. Хәзер ясләләргә чират җитте. Татарстан җитәкчелеге бу эшкә игътибарны арттырды. Федераль бюджеттә да алдагы ике елга 49 миллиард сум акча бүлеп бирелде.

Бик күпләр балаларга яшь ярымнан соң бирелә торган пособие күләменең бик бәләкәй булуыннан зарлана. Әнисенә инде эшкә чыгарга кирәк, ә сабыйны калдырырга урын юк. Өч яшькә кадәрге нәниләргә пособиеләрен бермә-бер арттырганда да начар булмас иде.

Бүген өлкән буын вәкилләренә дәүләтнең игътибары җитми. Сөйләшүләр күп, ә ярдәм аз. Нәтиҗәдә кешеләрнең уртача гомер озынлыгы һаман кыскара бара. Мондый хәлдән чыгу өчен бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы гомуми тәкъдимнәр әзерләгән. Ул беренче чиратта өлкән яшьтәгеләрне һәр елны диспансерлаштыруны күздә тота.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

ТАЛӘБЕНӘ КҮРӘ ҖАВАБЫ

Мәскәүнең, үзенә иминлек гарантиясе таләп итеп һәм җәмәгатьчелек фикеренә дә исәп тотып, моннан ай ярым элек АКШка һәм НАТОга юллаган килешү проектларына узган атнада, нәкъ ул теләгәнчә, язма вариантта җаваплар алынуы мәгълүм булды. Эчтәлекләрен бик үк ачып бетермәсәләр дә, компетентлы шәрехләрдән, таләпләр нинди тонда куелса, җавапларның да шундый ук өслүптә әзерләнүе аңлашыла. Игътибарны аларның бер үк көнне алынуы да җәлеп итә. АКШ дипломатиясе башлыгы Э.Блинкен әйтүенчә, Кушма Штатлар җавабы ике өлештән – Россиягә иминлек гарантиясе буенча тәкъдимнәрдән һәм аның үз-үзен тотышына Ак йортның борчылуларын белдерүдән тора. Җавап Украина, НАТО һәм Вашингтонның Европадагы союздашлары фикерен дә исәпкә алып төзелгән. Анда НАТОның «ачык ишекләр» сәясәтеннән чигенү булмаячагы турында ачык әйтелгән. Блинкен исә сөйләшүләр үткәрү өчен өметле юнәлешләрне дә күрсәткән. Алар рәтендә ул Европада ракеталар урнаштыруда контрольне көчәйтүне, шулай ук тотрыклылык вә ачыклыкны арттыруны атаган. Анынча, алдагы адымнар Россиядән, аның деэскалациягә әзерлегеннән торачак, ә АКШ исә теләсә нинди сценарийларга да әзер. Моны Блинкен, Европа белән берлектә, Россия икътисады вә финанс системасы өчен бик кыйммәткә төшә торган санкцияләр һәм гамәлләр планы әзерләнүе белән дә дәлилләгән.

НАТО җавабы да шундый ук рухта әзерләнгән. Альянс башлыгы Й.Столтенберг сүзләренә караганда, анда төп өч юнәлеш тәгаенләнгән: НАТО-Россия мөнәсәбәтләре (моның өчен Брюссельдә һәм Мәскәүдә вәкилләкләрне торгызу таләп ителә); Украинаның НАТОга керү ихтималы ягыннан Россиянең борчылулары (альянста һәр ил үз иминлеге өчен союздашларын ирекле сайлый дигән принцип яши, ә үз борчылуларын киметү өчен Россиягә иң элек Украина чикләрендә урнашкан гаскәрләрен алырга кирәк булачак); коралларны (Европада атом-төш коралы һәм урта ераклыклы ракеталар урнаштыруны) контрольгә алу, хәрби өйрәнүләрне ачык режимда үткәрү, шулай ук кибериминлекне ныгыту буенча хезмәттәшлек. Әлбәттә, НАТО үзенең «ачык ишекләр» сәясәтеннән һич кенә дә баш тартырга җыенмый, әмма Россияне үз гаскәрләрен Украина, Грузия һәм Молдовадан чыгарырга чакыра. Шул ук вакытта ул төбәктә үз көчләрен һәм аларның әзерлеген арттыру чараларын да күрә. Күренә ки, күп нәрсә Россиянең үзеннән тора, ә ул алган җаваплар аңа бөекдержавачыл омтылышларыннан арынырга да ярдәм итә ала. Беренче мәлдә Мәскәү алардан хәтта бераз аптыраштa да калды кебек. Аның тәүге реакциясе «Украина белән сугышу хәтта уебызда да юк иде» кебегрәк булды. Ә АКШ һәм НАТО җавапларында Мәскәүнең принципиаль борчылулары исәпкә алынмавы хакында Россия Президенты В.Путин үзе белдерде. С.Лавров исә аларга анализ нигезендә әзерләнгән тәкъдимнәр карар кабул итү өчен, Россия Президентына тапшырылачагы турында әйтте.

Хәлбуки, кайбер ишарәле фактлар да бар. Әйтик, АКШ һәм Бөекбритания, Европа Берлеге һәм НАТО илләре белән берлектә, Россия агрессиясенә каршы тору өчен аның икътисадына җитди зыян сала торган чикләүләр кертү һәм НАТОның көнчыгыш флангын ныгыту турында уртак фикергә килгәннәр. Байден Көнчыгыш Европа илләренә өстәмә хәрби көч җибәреләчәге турында да әйтә. Охшаш чаралар, әлбәттә, Мәскәү тарафыннан да күрелә. Тик ул моны «Союзная решимость-2022», яисә илнең 4 флотында (Тын океан, Балтыйк, Төньяк һәм Кара диңгез флотлары) үткәрелә торган планлы хәрби өйрәнүләрне сәяси вәзгыятькә туры китереп, гыйнвар-февраль айларына билгеләү аша эшли. «Бердәм Россия»нең Донбасска корал белән ярдәм итү турындагы чакырулары да юктан гына түгел. Шуның белән бергә, кайбер дипломатик чаралар да күрелә. АКШ-Россия очрашуының чираттагы этабын әзерләү өчен Э.Блинкен шушы көннәрдә С.Лавров белән аңлашырга җыенуын әйтә. Сөйләшүләрне нәтиҗәле итү өчен, АКШ җавабында Мәскәүгә аны бастырып чыгармаска киңәш ителүе дә игътибарга лаек. Зур сәясәттә Көнбатыш һәм Россиянең, капма-каршы позицияләрдән, әмма уртак максатларда эш итүен истә тотсак, ул киңәшнең мәгънәсе инде тагы да тирәнәя. Ә әлегә Вашингтон 31 гыйнварда БМО КШ кысаларында Украина буенча ачык очрашулар үткәрү башлангычы белән чыкты.

Фоат УРАЗАЙ.

Хиҗаб турында анык басма

1 февральдә, Бөтендөнья хиҗаб көнендә, Татарстан мөфтияте Казанның танылган мөслимәләрен, хатын-кызлар белән эшләүче оешмаларның җитәкчеләрен, абыстайларын, мөгаллимәләрен җыйды. Очрашуда мөселман эшмәкәре Радик Габдрахманов, танылган адвокат, Россия мөселманнарының юридик хокукларын яклау өлкәсендә тәҗрибә туплаган Руслан Нәгыев катнашты.

Кунакларны Татарстан Мөслимәләр берлеге җитәкчесе Наилә ханым Җиһаншина сәламләде. Чараның төп өлешендә Татарстан мөфтияте тырышлыгы белән бастырылган «Хиҗаб» белешмәлеге тәкъдим ителде. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин үз чыгышында, тарихи документларга нигезләнеп, 1917 елда үткән мөселманнар корылтаенда хиҗаб мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарлар, хиҗабның мәгънәсенә, тарихына, татар мәдәниятендә тоткан урынына ачыклык кертте.

– Кайберәүләр хиҗаб юк дип әйтсәләр дә, Коръәндә хиҗаб турында берничә аять бар, ул пәрдә дигәнне аңлата. XX йөз башында татарларда хиҗаб сүзе пәрәнҗәне аңлаткан. Шуңа Муса Бигиев, Галимҗан Баруди, Мөхлисә Бубый кебек галимнәребез катнашында үткән мөселманнар корылтаенда «безнең шәригатебездә хиҗаб кию ваҗиб түгел» дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Бүген исә, кызганыч, бу сүзгә нигезләнеп, татар хатыннары хиҗаб кимәгән, дигән ялгыш фикерләр әйтелә. Гәрчә корылтайның әлеге карарында пәрәнҗә күздә тотылса да. Революциягә кадәр яулыкны химар дип атаганнар. Коръәндә «Нур» сүрәсендә «химарларыгызны киегез» дип әмер бирелә, димәк яулык киярга кушыла. Хәзерге вакытта без хиҗаб сүзен яулыкка карата кулланабыз. Ләкин йөз ел элек хиҗаб сүзе пәрәнҗәгә карата әйтелгән. Безнең өчен мәгънә мөһим: димәк, яулык булган һәм аны кию фарыз, – диде ул.

«Хиҗаб» белешмәлеге Татарстан мөфтиятенең Голәмалар шурасы һәм «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан рус телендә әзерләп бастырылды. Әлеге басмада хатын-кызларга яулык киюнең фарыз булуы хакында Коръәннән, сөннәттән һәм фәнни хезмәтләрдән төп дәлилләр китерелгән.

«Хиҗаб» басмасы мөслимәләрнең генә өстәл китабы түгел, ул һөнәри эшчәнлекләрендә хиҗаб мәсьәләләре белән очрашып торган укытучылар, эшмәкәрләр, спортчылар, юристлар, судьялар h.б. җәмәгатьчелекләр өчен дә файдалы булачак.

Очрашу кысаларында Казан шәһәренең җиде районына баш абыстайлар тәгаенләнде. Алар халыкны ислам дине кануннары буенча яшәргә чакырып дәгъват эше алып бару, балалар бакчаларында хәләл туклану, мәктәпләрдә әхлак дәресләрен оештыру, аз керемле гаиләләргә ярдәм итү, социаль проектлар алып бару өчен җавап бирәчәк.

Бөтендөнья хиҗаб көне уңаеннан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды һәм Россия мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе хәйрия фонды ялгыз аналар, күпбалалы, үзенчәлекле балалар тәрбияләүче һәм авыр тормыш хәлендә калган аналар өчен тантаналы мәҗлес тә уздырды.

Дини рухлы әдәби бәйге

Татарстан мөфтияте Россия ислам институты һәм «Идел» журналы белән берлектә «Таян Аллаһка» әдәби бәйгесен үткәрә.

Әлеге конкурс Россия Федерациясендә яшәүче татарлар арасында талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатыннан уздырыла. Конкурсның быелгы өстенлекле темасы – Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы.

Бәйге өч этапта үтә. 1 нче этап – әсәрләрне кабул итү – 2022 елның 1 февраленнән 30 апреленә кадәр була. 2 нче этапта жюри әгъзалары әсәрләрне бәяли (1 май – 30 июнь). 3 нче этапта җиңүчеләрне билгеләләр (2022 елның сентябре).

Бәйгедә Россиядә яшәүче 10 яшьтән алып 45 яшькә кадәрге теләгән һәр кеше катнаша ала. Төп шарт – иҗат эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнмәү.

Бәйге өч номинациядә үтә: шигърият, чәчмә әсәр һәм публицистика. Конкурска тәкъдим ителгән әсәрләр һәм мәкаләләр татар әдәби телендә язылып, электрон вариантта кабул ителә. Авторлар эшләрен өч номинациянең берсенә генә җибәрә алалар, ягъни бер автор бары бер генә номинациядә катнашырга хокуклы.

Мюнхгаузен маҗаралары

«Әкият» Татар дәүләт курчак театрында Р.Э.Распе әсәре, К. Чуковский тәрҗемәсе буенча «Приключения барона Мюнхгаузена» спектаклен куйдылар. Авырлыклар алдында югалып калмый торган, курку белмәс, кыю, әллә нинди кыен хәлләрдән дә чыгу юлын тапкан Мюнхгаузен маҗараларын сәхнәләштерү җиңел булмаса да, режиссер Рафаэль Таһиров аны уңышлы башкарып чыккан. Спектакльдә нибары дүрт артист – С.Кузнецов, А.Карпеев, Н.Егорова, Е.Дмитриева катнашуга карамастан, сәхнәдә могҗиза тудырүга ирешкәннәр. Мюнхгаузенның ядрә өстендә Айга очуы, андагы хәлләр, сугыш күренешләре бик мавыктыргыч итеп сурәтләнә, курчакларны бик күп артистлар уйната дигән тәэсир кала. Курчакларны – рәссам С.Рябинин, музыканы композитор Ю.Чаплин иҗат иткән, биюләрне А.Егорова куйган.

«Барон Мюнхгаузен маҗаралары» – Л.Кэрроллның «Страна чудес Алисы», Р.Киплингның «Маугли» әсәрләре кебек үк, соңгы елларда иҗат ителгән кыю спектакльләрнең берсе. Күп тапкыр кино, мультфильмнарга төшерелгән маҗаралы бу геройларны гәүдәләндерү өчен хыял байлыгы кирәк. Н.Исәнбәтнең «Мырау батыр»ы да шулар рәтендә. Шул исемдәге телефильмнан соң мәшһүр татар классигы Н.Исәнбәтнең әсәренә яңадан әйләнеп кайту - шулай ук бик кыю адым.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

1 нче биттә – «Риваять» этно-төркеменең 10 еллык юбилей тамашасыннан бер мизгел. Салават Камалетдинов фотосы. «Татар-информ».

Мәдәният үзәгендә – шигърият бәйрәме

Бу көннәрдә татар җәмәгатьчелеге, әдәбият сөючеләр Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, танылган шагыйрь Зөлфәт Маликовның тууына 75 ел тулуны билгеләп үтә. Узган атнада Казан кооператив институтының Татар мәдәнияте үзәгендә дә шул уңайдан аның хатыны Фирая Маликова, кызы Кадрия, улы Фазыл, килене, «Сөембикә» журналы баш мөхәррире Лариса ханым, оныгы Нәфисә катнашында җылы кичә узды.

Татар мәдәнияте үзәгендә шагыйрь Зөлфәт Маликовның фоторәсемнәр күргәзмәсе дә оештырылган иде. Анда шагыйрьнең гаиләсе, дуслары белән аралашкан мәлләрендә төшереп алынган сурәтләр белән танышырга мөмкин.

Кичә шагыйрьнең шигырьләрен уку белән ачылып китте. Казан кооператив институты студентлары, Казанның төрле мәктәп-гимназияләре укучылары һәм укытучыларының шагыйрь әсәрләрен сәнгатьле сөйләве һәркемнең күңеленә хуш килерлек иде. Шигърият бәйрәме шулай ук видеоязмалар белән үрелеп барды. Әдәбият галиме Фоат Галимуллинның чыгышында шагыйрьнең югары кимәлдәге күләмле иҗаты, таланты искә алынды, галим сөйләвендә шигырьләре дә яңгырады. Зөлфәт Маликовка Аллаһыдан бирелгән талант нәсел тамырлары буйлап та килгәндер. Чөнки кызы Кадрия хатирәләре белән уртаклашканда, әтисенең әбисе Бибисәйдә абыстайның бәетләр чыгаручы булуы турында искә алды. Кадрия ханымга әтисенең иҗат итү процессын, шигырьләренең яратып укылуын, халкыбызның аңа ихтирамын күреп үсәргә насыйп булган. Лариса Маликова шагыйрьнең укучысына әйтәсе уй-фикерләре шигырьләрендә булуын, иҗатында күңелләрне борчыган барлык сорауларга җавап алырга мөмкин икәнлеген белдерде. Кичәдә катнашучылар шагыйрьнең җәмәгате Фирая ханымга багышлап иҗат ителгән «Һаман яратам» дигән шигыренә язылган җырны видео аша Габделфәт Сафин белән Рәфинә Ганиуллина башкаруында тыңлады. Быелның май айларында Зөлфәт Маликовка мемориаль такта ачылачагы да хәбәр ителде. Кичәне Татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе, чараны әзерләүче Флюра Абдуллина алып барды.

Сөембикә КЫЯМОВА.

Сүнмәс йолдыз яктысы

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры музеенда артист, драматург, режиссер Кәрим Тинчуринга (1887-1938) багышланган «Сүнмәс йолдыз яктысы» проекты кысаларында дәрес-очрашулар башлап җибәрелде. Дәресләр Кәрим Тинчуринның 135 еллыгы уңаеннан оештырыла.

Беренче дәрескә очрашуга Татарстанның халык язучысы, Тукай премиясе лауреаты Рабит Батулла килде. Тинчурин мирасын өйрәнүгә зур өлеш керткән әдип Казанның 13 нче мәктәп укучыларына биниһая зур әһәмияткә ия мәгълүматлар сөйләде. Рабит Батулла К.Тинчуринның актерлык, режиссерлык, драматурглык эшчәнлегенә аерым тукталды.

Укучыларны «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе» кебек үлемсез әсәрләренең язылу, куелу тарихы кызыксындырды. Рабит Батулла гомум татар әдәбияты, тарихына кагылышлы мәсьәләләргә дә игътибар юнәлтте. Мисал өчен укучыларга «Сак-Сок» бәетен, «Йосыф» кыйссасын укырга тәкъдим итте. 13 нче мәктәп директоры урынбасары Фидания Гобәйдуллина фикеренчә, «Сүнмәс йолдыз яктысы» циклы укучыларда татар теленә, әдәбиятына, тарихына кызыксыну уята.

«Сүнмәс йолдыз яктысы» проекты кысаларында дәресне театр музее җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Розалия Чабатова оештырды һәм алып барды. Рабит Батулла аның җитәкчелегендә театр музееның Тинчурин мирасын, иҗатын саклауда зур эшләр башкарганын искә алды, театр җитәкчелегенә Тинчуринның хатыны Заһидә ханым каберен карап торганы өчен рәхмәт белдерде.

Тинчурин театры музеенда мәктәп укучылары катнашында дәрес-очрашулар һәр җомга көнне уздырылачак. «Сүнмәс утлар яктысы»на галимнәр, артистлар, язучылар кунак булып киләчәк.

Алтын булсын иде

Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында яңа спектакль куелды. Кемдер аны концерт, дип әйтергә мөмкин. Театральләштерелгән тамаша, диюче дә ялгышмас. Кыскасы, яңа әсәрне һәркем үзенчә аңлый. Эчтәлеге дә тышкы сурәтенә охшаган. Биредә драматургия юк дисәң дә була. Шулай да мәгънәсе бөтенләй юк түгел – тамашачыны нәрсә ул миллилек, кем ул милли каһарман, болар безгә кирәкме-юкмы, юк икән, нәрсә кирәк, кебегрәк сорауларга җавап табарга чакыралар. Миллилекне алга сөргән өлкән буыннан көлү дә бар.

Әсәрне Л.Янсуар һәм Р.Гарипова язган һәм режиссер буларак Р.Гарипова үзе үк куйган да. Аңлашылганча, әсәр бүгенге көндә миллилек төшенчәсе тирәсендә буыннар арасында барган каршылыкны күз уңында тота.

Гәрчә спектакль «Бердәм Россия» партиясенең «Театр – балаларга» федераль проекты кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте гранты ярдәмендә сәхнәләштерелсә дә һәм программада «12+» дип язылуга карамастан, ул акылы формалаша төшкән өлкәнрәк тамашачыларга багышланган. Ни аяныч, грантка балалар өчен бер дигән спектакль куеп булыр иде. Тулы канлы спектакль карап үзаңын формалаштырган балага аннары «Алтынч{ае}ч»не күрсәтсәң дә ярый, акны карадан, яхшыны яманнан аерачак ул.

«Калеб» белән өйдәш булса да, Кариев театрының тамашачысы «Калеб» яшендәгеләр генә түгел икәнен, кече, урта һәм югары сыйныфта укучы мәктәп балалары шактый зуррак санда булуын һәм алар карарлык спектакльләрнең кирәгрәк икәнен онытырга ярамый. Моңа кадәр Кариев театрының тоткан кыйбласы дөрес иде, ул вазифаны тиешенчә үтәп килде – репертуарның 99 процентын татар язучыларының мәктәп программасына кергән әсәрләре тәшкил итте, татар классикасына зур урын бирелде. Мәктәптә тәрбия бирү юкка чыккан заманда, бу авыр вазифаны театр тулысы белән үз өстенә алды.

«Алтынч{ае}ч»не яшьләр яратып караса да, аны иҗат иткән иҗат төркеме һаваланмас һәм репертуар театры сынау полигонына әйләндермәс дип ышанасы килә. Үзләренең дә балалары беркөнне спектакль карау яшенә җитәчәк. Шулчак классикларыбыз пьесалары буенча куелган спектакльләрне яисә «Алтынч{ае}ч»не күрсәтерләрме икән?

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

● Грециянең Тасос утравындагы Мәрмәр һәм Вати комлыклары дөньяда иң матурлардан санала. Алар ком да, чуерташ та түгел, бәлки тоташ ап-ак мәрмәр вагы белән капланган.

● XX гасыр уртасында галимнәр фторның, теш эмаленнән минераль тозларның юылуын киметеп, кариестан саклавын ачыклаган. Шул вакыттан бирле кариесны кисәтү өчен АКШта суга фтор кушыла. Мондый судан теш аграк һәм ныграк була, нәтиҗәсе куллана башлап бер ай үтүгә үк күренә.

● Иң күп нефть ятмалары Согыд Гарәбстаны, Венесуэла, Иран, Гыйрак, Күвәйт, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, иң күп газ ятмалары Россия, Иран, Катарда урнашкан.

Яхшырак яшәргә өметләнәбез

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Пенсиягә чыккан кешеләр үзләрен ташландык дип санамасын өчен алар турында даими кайгыртырга, ярдәм оештырырга кирәк. Шулай эшләгәндә кешегә сәламәт тормыш рәвеше алып барырга, сәламәтлегенә зыян китерә торган гадәтләреннән баш тартырга җиңелрәк булачак. Бүгенге өлкән буын – нигездә сугыш чоры балалары. Алар дәүләт кайгыртуына лаеклы.

Вице-премьер Т.Голикованың белдерүенә караганда, алдагы алты елның һәрберсендә уртача пенсияләр күләмен меңәр сумга арттыру күздә тотыла. Әгәр бүген уртача пенсия 14 мең икән, 2024 елга аны 20 мең сумга җиткерү күздә тотыла. Әлбәттә, һәркемнең пенсиясе бер үк күләмдә булмаячак. Пенсиягә чыкканда эш стажы һәм хезмәт хакы күләме исәпкә алыначак.

Яңарак кына хөкүмәтнең тагын бер карары дөнья күрде. 1 сентябрьдән 8 яшькә кадәрле балалары булган ата-аналарга, эш стажлары нинди булуга карамастан, больничный максималь күләмдә түләнә башлый. Россиянең хезмәт министрлыгы белдерүенчә, әлеге яңалык илдәге 1,5 миллион ата-анага кагыла. Мондый түләүләр эш бирүчеләрнең чыгымнары артуга китермәячәк, чөнки акча турыдан-туры социаль иминият фонды бюджетыннан түләнәчәк. Моның өчен өстәмә документлар да җыярга кирәкми.

Белгәнебезчә, моңа кадәр вакытлыча эшкә яраксызлык өчен пособие күләме стажга бәйле иде. Хәзер исә кечкенә балалары булганнарга стажның күпме булуы «больничный» түләвенә бәйле түгел. Ә 8 яшьтән өлкәнрәк балалары булган ата-аналарга больничный элеккеге тәртиптә түләнәчәк, ягъни эш стажына карап.

Әлбәттә, гади халыкның тормыш-көнкүрешен яхшыртуга юнәлдерелгән чараларга күбрәк кирәк. Кызганыч, без алар белән бүген әлләни мактана алмыйбыз шул әле.

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында икенче буын щепкинчыларның берсе Татарстанның атказанган артисты Зөлфия Зарипованы матур гомер бәйрәме белән тәбрик иттеләр. Актриса тал чыбыгыдай нечкә биле, зифа буй-сыны, өлгергән иген кыры төсендәге алтынланып торган матур чәчләре белән тамашачыны сокландырды. Сәхнәдә ут чыгарып биюе күңелне дәртләндерде. Һәр яктан килгән артистканы ни өчен сәхнәдә бик аз күрәбез икән, дигән уй күңелдән китмәде.

Щепкинчы Зөлфия

Бер караганда, З.Әхтәмова бик бәхетле артистка. Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, Туфан Миңнуллин, этисе Әхтәм Зарипов һ.б. эзеннән 1984 елда Мәскәүдәге Щепкин училищесына укырга баруы, режиссер Ренат Әюпов, артистлар Илсөя Төхвәтуллина, Илдус Габдрахманов, Мәрьям Йосыпова, Раушан Шәриф, Айрат Арсланов, язучы һәм драматург буларак та танылган Әмир Камалиев белән иңгә-иң артист һөнәренең нечкәлекләренә төшенү – үзе мәртәбә. Училищены тәмамлап кайткач 1989 елдан зур вә бай тарихлы К.Тинчурин театрында иҗат итә башлау - шулай ук куанычлы хәл.

Зөлфиянең иҗат юлы уңышлы башлана. Уңышларның иң зурысы – олуг шагыйребез Габдулла Тукайның 110 еллыгына «Татарстан» телевидениесендә режиссер Әхтәм Зарипов төшергән 7 серияле «Каргышлы балачак» фильмында Бибимәмдүдә роле. Актриса нибары 24 яшендә Тукайның әнисен уйнау бәхетенә ирешә, һәм «Каргышлы балачак»ны күреп калган буын Бибимәмдүдәне Зөлфия Зарипова рәвешендә күз алдына китерәчәк. Әхтәм Зариповның бүтән фильмнары кебек үк, «Каргышлы балачак» та телевидениенең алтын фондына керде. Күренекле актерларыбыз Әзһәр Шакиров, Шәүкәт Биктимеров, Ирек Баһман, Фирдәвес Хәйруллина, Хәлил Мәхмүтов, Наил Әюпов, Әсхәт Хисмәт, Нуретдин Нәҗмиев, Наил Дунаев, Илдус Әхмәтҗанов, Наилә Ибраһимова һ.б. белән бергә уйнау Зөлфиянең үзе өчен дә зур мәктәп иде, билгеле. Беренче рольләреннән булса да, З.Зарипованың Бибимәмдүдә роле булып чыга. Бу урында күренекле галимебез филология фәннәре докторы Рифгать Әхмәтьяновның рецензиясеннән кайбер юлларны китермичә мөмкин түгел. «Бибимәмдүдә, авторлар карашынча, кешегә авырлык килгүен күреп, ярдәмгә ташлана. Бу – язмышка буйсыну гына түгел. Монда тәвәккәллек тә, кыюлык та, батырлык та сорала. Бибимәмдүдә үзенең бурычын - ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә ярдәм итүдә күрә һәм шулай эшли дә. Бибимәмдүдә характерын ачуга багышланган һәр эпизод

шушы фикерне раслый. Аның миссиясе – җирдә яхшылык артсын өчен яхшылык кылу. Бу җаваплы рольне уйнаучы артистка Зөлфия Зарипова тиеш булганнан арттырмый да, киметми дә, эпизодтан эпизодка бизәкләрне төрлеләндерә һәм тулыландыра барып, чын татар хатыны образын тудыруга ирешә... Көчле шәхес Бибимәмдүдә. Ул авырып үлгәндә дә, мескенлек тойгысы түгел, зур югалту тойгысы кичереп тетрәнәсең, һәм, һичшиксез, уйланасың: әлбәттә, анасыннан күчкән гүзәл сыйфатлар Габдулланы шагыйрь итүдә зур роль уйнагандыр. Бибимәмдүдә телефильмда иң камил эшләнгән, бөтен, төзек образлардан санала, һәм бу гүзәл образны тудыруы белән яшь артистка Зөлфия Зарипова театр-кино сәнгате тарихында тамашачылар күңелендә калу өчен тагын бер уңышлы адым ясады...» – дип язган ул.

З.Зарипованың иҗат биографиясенә тагын бер сәхифә өстәгән роль – Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы буенча төшерелгән «Габбас хәзрәт» телефильмында хәзрәтнең кызы Нурия. Биредә дә «Каргышлы балачак»та катнашкан яраткан актерларыбыз уйный. Габбас хәзрәт ролен Әсхәт Хисмәт башкара. Телефильм тамашачыга шундый ошый ки, «Идел кызы» исеме бөтенләй төшеп калып, әсәрне «Габбас хәзрәт» дип йөртәләр.

Актриса З.Зарипованың экран иҗаты үскәннән-үсә барып, «Урын», «Үзеңнеке – үзәктә», «Килен киленне сынар» һ.б. фильмнарда матур рольләр иҗат итељ. Сәхнәдә уйнар өчен укыса да, Зөлфия камерага төшү серләренә өйрәнә. Биредә сәхнәдәге кебек купшылык, кычкыру, чәбәләнү килешми, хис-кичерешләрне бер күз карашы, ирен чите белән белдерергә кирәк. Актриса боларны оста булдыра. Экран да Зөлфияне ярата.

Иҗат кичәсендә З.Зарипованы башта курсташлары котлады. Р.Әюпов, И.Төхвәтуллина, И.Габдрахманов... – кайсын гына алсаң да, сәнгатьтә абруйлы шәхес һәм шулар белән берррәттән сәхнәдә басып тору, аларның берсе булу – нинди бәхет! Аннары экран партнерлары Әзһәр Шакиров, Дания Нурлы, Әсхәт Хисмәт тәбрикләде. Бу сәхнә аксакалларының һәр сүзе – алтын, бриллиант. Һәм ул бриллиантлар, чәчкә бәйләмнәре сыман, бүген, әнә, нәфис кенә Зөлфиябезнең аяк очларына төшә.

Шул чак күңел яраткан артистыбыз Наил Шәйхетдиновны юксынып куя. Исән булса, Хуҗа Насретдиннарча хәйләкәр бер елмаеп Зөлфиябезне котламый калмас иде. Г.Зәйнашева әсәре буенча куелган «Гайфи бабай, өйлән давай!» спектаклендә шундый килештереп уйнаганнар иде ич. Зөлфия анда Гайфи бабайның оныгына кәләш булып килгән татарча вата-җимерә сөйләшүче, әмма мәрхәмәтле, ачык күңелле шәһәр кызы Маги-Маһинурны гәүдәләндерде. Театр сөючеләребез Наил Шәйхетдиновны сагынган, Ренат Шәмсетдинов, Зөлфия Зарипованы күрәсе килгән саен, интернетка кереп, бу спектакльне әле дә яратып карый.

Нииндидер үзгә бер иҗат кичәсе булды ул. Сценарий актриса белән әңгәмә рәвешендә уйланылган. Сорау-җаваплар арасында «Гауга» төркеменә кушылып Илүсә Хуҗина җырлап ала. Актрисаның сәхнәдә графинялар кебек горур утыруында гына да бу сәхнә өчен гадәти булмаган югарырак хис бар иде кебек. Зөлфия – Тинчурин театрында Щепкин училищесында укыган бердәнбер актриса. Өстәвенә, шәһәр кызы. Халыкчанлык белән дан тоткан сәхнәдә кичәнең үзгәрәк, нәзакәтлелек белән сугарылган рухы шуның белән аңлатып буладыр.

Нәзакәтле актриса кичәсеннән соң, берсеннән-берсе зуррак сәхнә йолдызларының сәламенә дә карамастан, күңелдә юшкын калды. Юбилей кичендә актерларның төрле спектакльләрдән монологларын, диалогларын күрәсе, ишетәсе килә. Кичә буе берәр бенефис-спектакль уйнасалар, тагын да әйбәтрәк. Әмма ни кызганыч, Зөлфиянең рольләрен, бигрәк тә соңгы еллардагыларын бармак белән генә санарлык. Дөрес, З.Зарипова хатын-кызга язган иң бөек, иң мәртәбәле хатын, ана булу ролен уңышлы башкарды. Бүген аның ире, горурлыгы улы бар. Әмма щепкинчы булмаса да, Зөлфиянең бу рольне уңышлы үтәячәгенә һичбер шик юк иде. Иң кызганычы, бүтән театрларыбызда гына түгел, сәнгать, мәдәниятнең бүтән өлкәләрендә дә шулай игътибардан читтә, тиешенчә бәяләнмичә әрәм булып калган шәхесләребез байтак. Театр, кино сәнгатьләрендә исә җитәкчедән бәйлелек аеруча зур. Һәр артистның аңа гына хас булган сөйкемле ягын күрә белү – үзе талант. Андый талантлы режиссерлар сирәк очрый. Бигрәк тә хәзер, театрга бер спектакль куярга дип килеп киткән, җиңел дан, акча артыннан куган яшь буын режиссердан ни көтәсең? Һәрбер спектакль артында артист, кеше язмышы торганын онытмасак иде...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга
4 февраль
№ 4, 2022

Йөрәк яраларын бәйләүче ШАГЫЙРӘ

Учларыма сал син йөрәгеңне,
Яраларын өреп бәйләрмен.

Шушы юлларда шагыйрә һәм язучы Дилә Булгакованың барлык күңел халәте сыеп беткән кебек. Аның шигырьләрен, нәсерләрен, хикәяләрен укыганда, башкаларның да борчу-хәсрәтләрен үзенең хисләргә бай һәм нечкә күңеле аша үткәрүен тоемламый мөмкин түгел.

Башкортстанның хәзерге Кырмыскалы районы Бозаяз авылында ишле (җиде баланың икенчесе), иманлы нигездә, үзе әйтмешли, бисмиллалы гаиләдә дөньяга килгән кызның балачагы сугыш һәм аннан соңгы иң авыр, ипи бик кадерле булган елларга туры килсә дә, ул тормышның башкалар күреп бетерә алмый торган сәгадәтле мизгелләренә игътибар итүчән булып үсә. Затлыгы, әдәби әсәрләр язарга, рәсем сәнгатенә таланты исә әби-бабалары аша тапшырылгандыр. Әнисе ягыннан булган Ждановлар нәселе шәҗәрәләрендә 70 имам булуы теркәлгән. Атаклы мәгърифәтче, шагыйрь Хөснетдин бин Шәмсетдин Ягъфәр (1767-1869) дә – шушы нәсел агачында. Гаилә тамырларының тагын бер халыкка мәгълүм шәхесе – Е.Пугачевның дусты Канзафар Усаев.

Дилә, укырга-язарга өйрәнгәнче үк, беренче шигырен иҗат иткән, картәнисе һәм әнисенең кул эшләренең матурлыгына, нәфислегенә мөкиббән китеп, үзе дә рәсемнәр ясарга, күзе төшкән матур күренешләрне сурәткә төшерергә яраткан һәм рәссам булырга хыялланган кызчык була. Әмма Бөек Ватан сугышында кан коешларны күргән әтисе Хәмзә абзый да: «Хатын-кыз рәссам булмый ул!» – дип, кызының бу юлдан китүен теләми. Дилә шәфкать туташы һөнәрен сайлыйсы итә һәм 40 елга якын гомерен медицинага багышлый, әмма үкенми. Бу да нәселенең икенче тармагыннан бүләк ителгән һөнәр. Чөнки картәтисе Турьян карт Казанда белем алып кайткан табиб булган, авылдан авылга йөреп, кешеләрне дәвалаган.

Дилә дә рәсем ясау, шигырьләр язу белән күңеленә тынычлык тапса да, картәтисе юлыннан китә. Салават химия комбинатының санитар частенда, балалар бакчасында шәфкать туташы булып эшли, Башкортстан Эчке эшләр министрлыгына караган дәвалау учреждениеләрендә, алты ел төрмә хастаханәсендә тоткыннарны дәвалый. Әмма кайда гына хезмәт куйса да, шигырьләр язуыннан туктамый. Беренче иҗат җимешләре балалар бакчасында эшләгәндә үк телгә керә, шигырьләре, әкиятләре газета-журналларда дөнья күрә башлый. Язганнарының матбугатта басылып чыгуы, җырларының халык арасында танылуы аны иҗатка тагын да рухландыра. Алга таба Дилә Булгакова шигырьләр, нәсерләр, хикәяләр, пьесалар, юморескалар, парчалар язуын дәвам итеп, прозада да, шигърияттә дә бердәй илһамлы иҗат итүче талант иясе булып танылa. Дилә ханымның мәктәп елларында ук беренче мәхәббәте булган егеткә багышлап язган «Кыр казлары» («Син онытма жирдә мин барын») дигән җыры бүгенге 50-60 яшьлек кешеләр яшьлекләрендә иң яратып тыңлаган һәм моңланган көйләрнең берсе иде. Бүген дә популяр бу җырны ул елларда яраткан артистыбыз Фидан Гафаров башкарды.

Дилә Булгаковага татар теле һәм әдәбияты буенча белем алырга насыйп булмаса да, иҗади сәләтен язучы Нәҗип

Асанбаев оештырган әдәби иҗат түгәрәгендә чарлый. Иң беренче җыентыгын секция утырышында тикшергәндә, тәҗрибәле әдипләр «Яз, сеңлем, син әдәбиятка китмәс өчен килгәнсең», – дип рухландыра. Наҗар Нәҗми Д.Булгакованың нокта, өтерләре урынында булмавына игътибар итеп, «Белемсез, әмма талантлы шагыйрь», – дип ярым шаяртып әйтә торган була.

Хәзерге вакытта Дилә Булгакова күп кенә шигъри һәм проза әсәрләре, балалар өчен әкиятләр, ике йөзләп җыр авторы. Алар арасында «Ай гүзәлем, Айгизәм», «Гашыйк бул», «Зәңгәр күзле кызны сагынам», «Серле чишмәм», «Учларыма сал син йөрәгеңне» кебек аеруча популяр булганнары да хәтсез. Алар Башкортстан һәм Татарстанның танылган артистлары Зөһрә Сәхәбиева, Рөстәм Асаев, Идрис Газиев, Җәмил Әбделманов, Илһам Вәлиев, Радик Динәхмәтов һ.б. башкаруында җырмоң сөючеләргә барып ирешә. Бүгенге көндә язучының ике дистәдән артык китабы басылып чыккан. Алар арасында «Сер», «Скрипка моңы», «Намазлыгым җәйдем», «Гәрәбә», «Учларыма сал син йөрәгеңне» кебек әдәбият сөючеләр күңеленә хуш килгән басмалар бар. Китапларның исемнәреннән үк күренгәнчә, язучының тематикасы шактый киң. Дилә ханым каләменнән төшкән әсәрләр Башкортстан китап нәшриятында чыгучы татар дәреслекләрендә дә урын ала.

Язучы һәм шагыйрәнең әсәрләрендә геройның иң тирән эчке кичерешләре ачыла, геройларының садә-саф хисләре сокландыра, кайберсенең гаять авыр язмышы озак вакытлар уйландырып йөртә. Д.Булгакова әсәрләрендә милли тәрбия, гореф-гадәтләребезгә, табигать күренешләренә игътибар итә. Әйтик, аның шигырьләрендә каеннар, өянкеләр, чыршы-имәннәр, туган йорт, табигать фасыллары, хайваннар һ.б. аерым образлар булып кереп киткән.

Бу дөньяда ташның була күп
төрлесе:
Шомарганы, ярылганы, иң серлесе.
Кайчагында таш астыннан
елан чыга.
Көтмәгәндә таш астыннан
елан чага.
Гәүһәр бу, дип үрелгәнче уйла башта,
Гади таш та охшаш була
асылташка.

Ә кайвакыт шагыйрәнең ирләрчә нык итеп әйткән фикерләре сискәндерә.

Җимермәгез, кимермәгез
Җирне!
Шушы җиргә кайтасы бар,
Мәңгелеккә ятасы бар.

Дилә ханымның хикәяләренең геройлары – еш кына авылда гомер кичергән төрле һөнәр ияләре. Алар арасында зирәк әбекәйләр дә, укытучылар да, яшь-яшь кызлар да бар. Әмма аларның һәркайсының эчке дөньясы гаять бай, хисле.

Язучының «Төрмә циклы» хикәяләре аерым әһәмияткә ия. Алар «Үрмәкүч» дип аталган җыентыкта дөнья күргән. Укучылар тарафыннан аеруча яратып кабул ителгән бу гыйбрәтле язмышлар турындагы китапны тәнкыйтьчеләр уңай бәяләгән. Хикәяләреннән күренгәнчә, ул зиндан хастаханәсендә эшләгәндә төрле язмышлы кешеләр белән очраша. Әмма аларны ул, төрмәдә дә - адәм балалары, дип кабул итә, кызгана. Аларның үтенече буенча әнкәеннән догалар яздырып, аларга тапшыра торган була. Әлбәттә, моңа шагыйрәне 25 ел утырган тоткыннарның, камерада ураза тотып, намаз укыганнарын күрүе дә этәргәндер. Дилә ханымның күңеленә аларның Раббебызны зурлавы аеруча хуш килгән. Төрмә хастаханәсендә аның кизү тору чираты җитүен көтеп ала торган булалар. Д.Булгакова Аллаһының үзенә хаҗга юл ачуын зиндандагылар белән аларны кимсетмичә сөйләшүенә, тоткыннарга кулыннан килгәнчә, ярдәм итәргә тырышуына, сабырлыгына бер бүләк дип кабул иткән. Аңа көтмәгәндә хаҗга юллама бирәләр. Мәккә юлларында йөргәндә дә «Раббем, кешеләрнең гомерләре бик аз. Баласын тапкан анага кайгы күрсәтмә, газизе зинданнарда тилмермәсен, адәм балалары ялгыш юлларга басмасын», - дип дога кыла. «Мин яхшылык эшләргә тиеш, дигән уй күңелемнән һичкайчан чыкмый», – ди ул.

Дилә Булгакованың соңгы дистә елдагы иҗатында дини темага әһәмият бирелүе дә кешеләргә барысы да Аллаһы кулында булуын, кылган изгелекләребезнең юкка чыкмавын аңлатырга тырышуыннан киләдер. Аның тырышлыгы һәм матди ярдәме белән төрле авторларның динебезгә кагылышлы хезмәтләре, хикәя-очерклары тупланган «Туфрагында Бөек Болгарның», «Аллага шөкер», «Фанилыктан мәңгелеккә күчү» дигән җыентыклар да дөнья күргән. Дилә ханым шулай ук, Уфа шәһәренең «Ихлас» мәчетендә попечительләр советы әгъзасы буларак, мәхәлләдә уздырылган барлык дини бәйрәмнәрне, кичәләрне, чараларны оештыруда катнаша.

Дилә Булгакова – хәзерге вакытта үзенең бәхетле гомеренә шөкер итеп яшәүче шагыйрә. Уфа шәһәре прокуроры булып хезмәт куйган тормыш иптәше Зәки ага белән Римма һәм Роза исемле ике игезәк кызлар тәрбияләп үстергәннәр. Ул бүген ирен һәрдаим «Бик әйбәт кеше булды», – дип искә ала. Шул ук вакытта Дилә Булгакова, оныклары уңышына сөенеп, аларны кайгыртып яши торган картәни дә. Арада әдәби иҗат белән шөгыльләнүче оныгы да бар икән, ә берсе рәсем сәнгате белән мавыга. Дилә ханым үзе исә шигырь-хикәяләр язудан тыш күңеле тартылган рәссамлык белән дә шөгыльләнә. Аның бу сәләте чигү сәнгатендә чагылыш таба. «Тукай», «Сөембикә-ханбикә» картиналарын, сәйләннәр белән бик күп калфаклар чиккән, кульяулык-ашъяулыкларның исә саны-исәбе юк. Дилә ханымның юбилей кичәләрендә хатын-кыз бәйрәмдарга калфак бүләк итүенә инде күнегеп беткәннәр. «Башкалар кебек чәчәк бәйләмнәрен тапшыра алмыйм. Тамырыннан өзеп алынган гөлкәйләрне кызганам», – ди ул.

Инде тугызынчы дистәсен ваклаган шагыйрәнең активлыгына да кайберәүләр кызыгырлык. «Ихлас» мәчетендә дини чаралар үткәрүдә катнашу белән бергә, «Сәхибҗамал», «Ак калфак» татар хатын-кыз оешмалары әгъзасы буларак та эшчәнлек алып бара.

Сөембикә КАШАПОВА.

* * *

Томаннар артында калган
Безнең газиз авыллар...
Тик күңелдә күтәрелә
Сагыш атлы давыллар.

Күз алдына килеп баса
Арба эзе юлларда...
Җәй... бакчага чумган чаклар
Кыяр, кишер урларга...

Кайда калды бәбкә көткән
Авылымның инеше?!
Еллар киткән. Гомер үткән,
Мин инде бүтән кеше...

Түбәтәйле такыр башым,
Чебиле аякларым,
Ак Чишмәдән Игенчегә
Очкан ат – таякларым...

Ул кара малай соң минме?!
Мин андый җитез түгел...
Бастылар бармак очына
әнә камышлар –
һәммәсе дә иске белеш,
якын танышлар...
Уянды күк. Тәңре аты
биеде ялт-йолт...

Күзем ачтым. Күз алдымда
ап-ак Идел-йорт.

ТУГАН НИГЕЗ

Караңгы һәм моңсу бер өй бар
Урманнар эчендә, салада.
Ташландык бу өйнең йөзендә
Охшашлык бар ятим балага.
Урманнар моңлы җыр көйлиләр,
Яфраклар биилəр күгендә...
Ташландык шул өйгә бик килә,
Кайтасым бик килә бүген дә.
Ул матур, күңелле йорт иде,
Мал тулы каралты, амбарлар...
Бакчада алмагач, карлыган –

Әхмәт ГАДЕЛ

Исәрләнде син дип аңым,
Рухым күктә, җирдә – саным.

Төннәргә мин ярагапым,
Сергә җиңел карагапым...
Сиңа рухны өреп-өртеп,
Алдамадым – алданганмын.

ТОР!

Тор, абыстай, уян инде,
Гаҗәп, ничек йокы җиңде.
Керфеккә керфеген инде?!
Тор, абыстай, шатлык килде!

Ятагыңда ястык җылы,
Эчләрендә мамык тулы,
Шундамы мәхәббәт юлы,
Таба алдыммы бу юлны?!

Кара төндә сөю рәхәт,
Җанга иңмәсен җәрәхәт,
Тор, тор, җаным, уян җәһәт,
Сабырлыгым бетте инде.

Нинди заман, нинди заман иде: Күңелләргә яман кырау тиде...

(Танылган шагыйрь Әхмәт Гаделнең тууына 80 ел)

Тик төннәрен янә иңли
Туган ягымны күңел...

НИК? БЕЛМИМ...

Нури Арсланга

Ник? Белмим... Урамда ат күрсәм,
Күңелем сагына даласын.
Җилләргә таратып чәчләрем,
Бик килә кояшта янасым!

Кая ул әкияти замана?!
Көч уйный тәнемдә, беләктә...
Кем мине, аерып даламнан,
Әйтегез, өйрәткән әдәпкә?!

Һәм нигә яшендәй йөрәгем,
Күзләрем балкыта таңнарны?
Күңелем очына чүлләргә,
Тик мине чүл, дала аңлармы?

Ник? Белмим... Урамда ат күрсәм,
Күңелем сагына даласын.
Җилләрдә, киңлектә, сафлыкта
Бик килә бер шашып аласым.

* * *

Гариф Ахуновка

Кич. Эңгер. Елга суының
саллы агышы...
Су буендагы урманның
татлы сагышы...
Мин. Хисем.
Моңлы авазым:
– Әй-һәй, урманым! –
Яшьлегемә багышланган
тиңсез корбаным!
Җавап кайтар бер сала...
Юк, кайтмас аваз! –
Талгын суда агып киткән
Чәчәкле шат яз!..
Хозыр Ильяс учаклары,
Болгарга сәлам...

Йөгерә-йөгерә
кәгазь буйлап,
сүз эзли каләм...
Шулвакыт шатлык күңелдә...
Уянды урман,
һай-һайлап шаулый башлады,
җан-рухым, куан!

Ярларда кеше уянды –
яңгырый аваз:
Тәүерләр, хазар, команнар...
болгар вә суаз...

Һәммәсе моң-уйга талганнар...
Әй гомер, дәрьядан киң, көчле,
Юк, сине туктатып һич булмый.
Тик хисләр, сагыну хисләре
Саф кизләү суыдай гел ургый.
Төшемдә шул йортка кайтам да
Сөяләм ап-ак зур миченә...

Таңнарның саф, гүзәл булуын
Тәгаен аңлыйбыз кич кенә...

НИНДИ ЗАМАН ИДЕ

Нинди заман, нинди заман иде:
Җаннар янды яладан, көйдә...
Ялагайлар – елан балалары –
Кеше кыяфәтен алып йөрде...

Нинди заман, нинди заман иде:
Яхшылыкны яманлык җиңде...
Илнең батырлары, агалары
Кечерәйде хурлыктан, инде...

Нинди заман, нинди заман иде:
Күңелләргә яман кырау тиде;
Туып-үскән газиз җирләреннән
Халыкларны сөргән еллар килде.

Җир елады, елады Кояш...
Туктамаган әле күз яше!
Нинди заман...
Нинди заман иде...

АТ МОНОЛОГЫ

Бәйлә,
авызлык каптыр!
Без кыйналган мең тапкыр!
Без туралган, чәйнәлгән...

Ләкин шушы ачы җиргә
йөрәк белән бәйләнгән.

* * *

Тормыш дигән олы кырда
адаша язганым бар.
Биек күккә очып җырдай,
саташа язганым бар:

Дусны – дошман, ә дошманны
дус дип ялгышканым бар.

Яманга күнеп, яхшыга
ялгыш карышканым бар...

ДОГА

И бөек, и киң күңелле,
И газиз мескен халкым,
Әгәр күрсәм бүтәнеңне,
Эчемне били ялкын!

Тырышасың-тырмашасың,
Тормакчы тезләреңнән.
Базарларда эссе, салкын,
Моң ага күзләреңнән.

Моң елгасы – тозлы елга,
Агыза гомереңне.
Йә, кемнәрне җылытасың
Яндырып күңелеңне?!

Онытты ир җан сөйгәнен,
Назламый ирне хатын.
Син бит бүген искәртәсең
Ач, ябык сугыш атын.

И газизем, и бәгырем,
Тик син дип дога кылам:
Бир ирек һәм бир азатлык –
Бәхет бир, Раббым-Аллам!

Әллә кемнәр табынында
Җанның хәләл азыгы.
Бу кадәре интеккәннең
Каламы соң языгы?!

Кичер, кичер, кичер, Аллам,
Яшәсен газиз халкым.
Гөнаһлары булса – алам,
Ялмасын мине ялкын!

СИНДӘ КАЛДЫ

Серебезне төннәр алды,
Әмма күңелем синдә калды.
Хыял миндә, җаным синдә...
Татлы уйлар хискә талды.

Һәм мин эзлим серле төнне,
Сихерләдең, бәгърем, өнне,
Адаштырдың, наян, аңны,
Назларыңа чумган төнне.

Һич уйламас мине күргән,
Соңгы дәртне сибәм, түгәм,
Соңгы сүзем оча сиңа,
Кызган, гүзәл, җанда йөгән!

Ярым, ярым – ярамаңым,
Кызган таңым – нурлы таңым,

Рәхмәтләр яусын күкләрдән,
Син татлы, җаным, күпләрдән,
Төннәремне буш үткәрмәм,
Пешкән җимешнең син тиңе!

Диңгездә дулкын йөргәндәй,
Чүлләрдә сәмум өргәндәй,
Күкләрдә яңгыр иңгәндәй,
Силдәй агып йөрик инде.

Бер Аллаһ биргән бәйрәм бу,
Галәмне биләр бәйрәм бу,
Мин – аучы, ә син җәйрән бул,
Йокыны мәхәббәт җиңде!

* * *

Кар-бураннары кайнар,
Кыш егетләрне сайлар.
Кырда калсаң төннәрен,
Җылытмас төшеп айлар!

Аралык ай – декабрь,
Язга таба китә бир!
Кышкы җилдә җан көйсә дә,
Тормыш юлын үтә бел.

Боз эретер ут синдә,
Көн җылытыр ут синдә.
Йолдызлары белән күкне
Күтәрерлек сут синдә!

Кырык чүлне үткәнсең,
Кырык диңгез кичкәнсең.
Кырык кырның уртасында
Өч юрганы җиккәнсең!

Кыш бураннары уйный,
Тормыш бураны кыйный.
Ачылар күбрәк булса да,
Татлысыннан җан туймый.

* * *

Сыен минем кочагыма,
Газиз күңелем пәрәсе.
Мәңге сүнмәс утка төштем,
Табылырмы чарасы?

Сөям, дигән саен, җаным,
Бакмас булдың йөземә...
Бу мизгелләр гел-гел килмәс,
Ышан әйткән сүземә.

Калсын читтә дөнья гаме,
Җанымда давыл купты! –
Җылы җәннәт җиле белән
Кушылды тәмуг уты...

Ильяс Камал – композитор, музыкант, дирижер. Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе солисты, Тинчурин театрының баш дирижеры, Татарстан һәм Россия композиторлар берлекләре әгъзасы. М.Җәлил исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Ильяс Камал – бүгенге татар иҗатчылары арасында иң нык җигелеп эшләүче һәм шул ук вакытта иң тыйнагыдыр, мөгаен. Күз алдыбызда үсте, ныгыды, иҗатчы булып танылды.



«ДӨНЬЯГА ЧЫГАРЫРЛЫК

Санкт-Петербург каласында татар зыялылары гаиләсендә туып-үскән талантлы бала Казанга – Сара Садыйкова исемендәге конкурска килә һәм анда виолончельдә композиторның әсәрләрен башкара.

Сара апаның кызы Әлфия Айдарская аны шунда атаклы виолончель остасы Лариса Маслова белән таныштыра. Ә ул исә егетне Казан музыка көллиятенә укырга килергә чакыра. Тугызынчы сыйныфны тәмамлаган 15 яшьлек үсмер чакыруны кабул итә: музыка көллиятендә укый башлый. Аның артыннан Камаловларның бөтен гаиләсе Казанга кайтып төпләнә. Виолончельдә уйнау осталыгын чарлау белән бергә, Ильяс оркестрлар өчен әсәрләргә аранжировкалар ясау белән дә мавыга. Моны күреп, остазы Лариса ханым аны консерватория профессоры Борис Николаевич Трубин белән таныштыра. Ул да егетнең талант иясе икәнен тиз чамалый – консерваториягә укырга чакыра. Ильяс берьюлы ике факультетта укыды: виолончель серләрен өйрәнүне дәвам итте һәм композиция теориясе бүлегендә дә белем алды. Шәкерт чагында ук виолончелистларның Ростропович исемендәге халыкара конкурсында 3 нче урынны алып кайтты ул. Ә Саранскида үткән Бөтенроссия конкурсында исә беренче урын яулады.

Ильяс Камал – виртуоз музыкант кына түгел, йөзләгән инструменталь музыка әсәрләре авторы да. Аның кыллы оркестр өчен «Кыпчак увертюрасы»н, Илһам Шакировка багышланган симфоник поэмасын, торба һәм фортепиано өчен язылган «Идел-Урал» сюитасын һ.б. әсәрләрен тыңлаганда тирән милли хисләр белән сугарылган югары сәнгати әсәрләрне яшь кенә егет язганына ышанасы да килми. Аның яшьтәшләре космополит рухлы музыкага баш-аяк чумып, халыкара конкурсларда җиңү турында хыялланганда, Ильяс милли музыкабыз байлыгын бөртекләп өйрәнде. Китапханәләрдән чыкмыйча утырып, үзендә бик күп әсәрләрнең партитуралары коллекциясен туплады, татар музыкасының үсеш этапларын энәсеннән җебенә кадәр өйрәнде. Милли тамырларга сусаган күңеле шушы байлыкларны ачудан, өйрәнүдән рәхәт чикте, үсте, тагын да зиннәтләнде.

Белем җыю белән бергә халыкка да хезмәт итте ул. 2014 елдан бирле Ильяс Тукай исемендәге филармониядәге әдәби-музыкаль лекторийда солист буларак чыгыш ясый. Яңа әсәрләр язу һәм әсәрләр оркестровкалау эшен дә сөеп башкара. Бүген Ильяс тарафыннан эшкәртелгән әсәрләрне Татарстандагы кайсы гына оркестр уйнамый икән? «La Primavera» камера оркестры, «Яңа музыка» оркестры, Фольклор музыкасы ансамбле, «Татарика» оркестры һ.б. коллективларның репертуарында ул эшкәрткән йөзләгән әсәр яңгырый.

«Минем Такташ» камера операсы белән дә музыка сөючеләрнең игътибарын җәлеп итте сәләтле егет. Белемен тирәнәйтүдән дә туктамады, Казан консерваториясенең ассистентура-стажировкасын тәмам итте. «Башмагым Jazz» музыкаль комедиясенең уңышлы музыкаль куелышыннан соң Ильясны К.Тинчурин театрына баш дирижер итеп эшкә чакырдылар. Бу эшләреннән тыш, ул әле консерваториядә укыта да – Кыллы квартетлар, камера ансамбльләре кафедрасында шәкертләр тәрбияли.

– Бу кадәр өлкәдә эшләргә ничек өлгерәсең? – дип сорыйм, чын күңелдән гаҗәпләнеп.

– Бу эшләр бер-берсенә комачауламый бит, киресенчә, алар бер-берсен тулыландыра. Музыка иҗат итүдә тоткарлык башланса, мин оркестровкага керешәм, уйныйм. Иң зур кыенлык – графикларны туры китерүдә. Биш сәгать йокы эләксә, шәп инде. Музыка язарга вакыт аз кала, төнлә торып та язып куям. Җырларны аз язам, күбрәк камера-инструменталь һәм оркестр өчен әсәрләр иҗат итәм. «La Primavera»да икенче дирижер да әле мин, андагы төп эшем – оркестровкалар язу.

Ильяс оркестр өчен эшкәрткән әсәрләр аерылып тора: ул музыка мирасына бик сак карый, милли аһәңнәрне кайберәүләр кебек ботарламыйча гына сәнгати яңгыраш бирә белә. Бу өлкәдә аның осталыгын «Безнең җыр» иҗат лабораториясенең гала-концертында күреп куандык. Ильяс әлеге чараның музыкаль җитәкчесе булды, барлык җырларны үзе оркестрга салды һәм үз оркестры белән әлеге чараның искиткеч бер бизәгенә әйләнде. Татар җырларына һәркем аның кебек сак һәм йөрәк җылысы белән кагылса иде дә бит. Ләкин ни кызганыч, «Үзгәреш җиле» кебек сансыз миллионнар сарыф итеп уздырылган чараларда да халык бәгыренә якын җырларны яңартабыз дип, йөнлары йолкынган шыксыз үрдәк бәбкәсе хәленә төшерәләр. Ильясның бу мәсьәләдә үз фикере бар:

– Джаз безгә ят димәс идем. Бу юнәлештә А.Монасыйпов, Р.Ахиярова һ.б. композиторларыбыз уңышлы гына иҗат итте. Әмма элек иҗат ителгән җырларны, халык җырларын акыл һәм күңел белән эш итмичә, белмичә үзгәртүгә мин каршы. «Үзгәреш җиле»н мин кирәксез әйбер димим, чөнки хәзер оркестрлар да калмады, инструменталь музыка сирәк яңгырый. Әмма бу эшне читтән кешеләр чакыртып эшләтү дөрес түгел, киресенчә, безгә үз оркестрларыбызны булдырырга, үстерергә кирәк. Булганнары да юкка чыкты бит. Әйтик, Үтәй җитәкчелегендәге оркестр, халык уен кораллары оркестры… «Үзгәреш җиле»ндә дә уңышлы гына эшкәртмәләр бар. Әмма андагы күпчелек әсәрләр белән аңлап эш итмәгәннәре күренеп тора. Читтән килгән кешеләр безнең музыканы белми, аңламый, телне дә аңламый. Халык җырларын, композиторлар җырларын нинди дә стиль калыбына җайлаштырып үзгәртүгә мин каршы. Автор нинди стильдә иҗат иткән, шулай башкару кирәк.

Ильяс талантлы композитор һәм музыкант кына түгел, оештыру сәләтенә ия җитәкче дә булуын раслады. Кыска гына вакыт эчендә ул теләсә кайсы концертны бизәрлек оркестр туплый алды.

– Мин Тинчурин театрына баш дирижер булып килгәндә анда 5-6 кешелек ансамбль эшли, спектакльләрне музыка белән бизи иде. Аларга өстәп, коллективны көчәйттем, уен коралларын да, башкаручыларны да үзем сайладым. Алга таба да оркестрны үстерәсем килә, кызганыч, әлегә мөмкинлекләр юк. Хәзер оркестрда 12 кеше. Концертлар вакытында өстәмә музыкантлар чакырабыз. Кайбер концертларны тулысы белән алып бардык. Әйтик, «Безнең җыр»ны тулысы белән үз көчебез белән эшләп чыктык. Тинчурин театрында күптән түгел яңа проект башлап җибәрдек: «Татар классикасы җәүһәрләре» дип аталган концертлар циклы. Бу – безнең оркестрның проекты, инде ике концерт бик уңышлы үтте. «Башмагым» музыкаль комедиясенең беренче куелышына 80 ел тула, өченче концертны шул датага багышларга уйлыйбыз. Концерт консерваториянең опера студиясе белән берлектә оештырыла, анда комедиянең классик куелышыннан өзекләр, «Башмагым Jazz» спектакленнән дә фрагментлар булачак.

Татар музыка хәзинәсенең байлыгы белән горурлансак та, йөзек кашыдай әсәрләребез сирәк яңгырый шул бүген. Классик музыка байлыгыбыздан, инструменталь музыка яңгырашыннан мәхрүм буын

МУЗЫКАБЫЗ БАР»

үсеп килә. Эфир дулкыннарын, зәңгәр экраннарны баскан шырдый-быргый эстрададан туеп киткәч, барып җан сусаган көйләрне тыңларга иде дә бит – андый Музыка театрыбыз бүгенгә кадәр юк! Бу театр хакында хыяллар әллә кайчаннан бирле күңелләрне җылытып тора, ләкин һаман да Музыка театры нигезләнми. Бу хакта Ильясның да фикерен белешмичә кала алмыйм.

– Музыка театры безгә бик кирәк. Куярга әсәрләр дә, эшләргә теләге булган композиторлар да бар! Дәртләнеп эшләргә теләгән җырчыларыбыз күпме! Бу театрны көтүче тамашачы да күп. Әмма оештыру ягы, матди нигезен булдыру без иҗатчылардан гына тормый шул. Башка зур шәһәрләрдә (Мәскәү, Санкт-Петербург) музыка театрлары бар һәм бер генә дә түгел. Аларның репертуарлары музыкаль әсәрләрдән генә тора. Бер дигән җырчыларыбыз да бар бит, консерватория ел саен әзерләп тора. Күбесе үзенә урын таба алмыйча, банкетларда йөрергә, эстрадага китәргә мәҗбүр. Кемнәрдер мәктәпләргә укытырга урнаша. Музыка театры ачылу күп милли кадрларыбызга эш урыны булдырыр, җырчыларны да, инструменталь әсәрләр язучыларны да туплаучы үзәк була алыр иде, – ди ул күпләрнең уртак фикерен белдереп. – Бина мәсьәләсен дә хәл итәргә була. Әйтик, Камал театры яңа бинасына күчкәч, иске бинасына Кариев театры урнаша, ә Кариев театры бинасында Музыка театрын ачып җибәрергә булыр иде. Аякка басканчы, ул анда эшләп тора ала. Аннары, әлбәттә, музыка театрына яңа бина кирәк булачак, чөнки идеаль акустика, техник мөмкинлекләр булырга тиеш. Мюзикл жанрының үз таләпләре бар, анда оркестр чокыры да, сәхнә техникасы да кирәк.

– Татар милли музыка сәнгате 90 нчы еллар башына кадәр гел үсештә булган, барлык жанрлар диярлек үскән. Ә хәзерге хәле ничек музыка сәнгатебезнең?

– Татар музыкасы әле дә үсештә. Иҗатчыларыбыз күп. Ләкин аларны үстерергә, халыкка танытырга кирәк. Шул ягы җитеп бетми. Үсеш булса да, киң җәмәгатьчелеккә чыкмый икән, аны халык белми дә кала. Зур күләмле җитди әсәрләр языла, ә аларны халык белми. Классик музыка байлыгыбызга, тулы канлы музыкаль әсәрләргә пропаганда бөтен яклап оештырылырга тиеш. Бу өстән оештырылса гына нәтиҗәле булачак. Җырчыларыбызны, музыкаль әсәрләрне халыкка җиткерерлек проектларыбыз күбрәк булсын иде. «Безнең җыр» – әнә шундый проект иде.

– Музыка хәзинәбезне үзебезнең яшь буын да белми, дөнья күләмендә чыгару турында да уйлаучы юк…

– Татарның дөньяга чыгарырлык музыкасы бар. Без бит булган музыка хәзинәбезне бәяләп тә бетермибез. Безнең бердәнбер татар музыкасы симфоник яңгыраштa башкарылучы «Мирас» фестивалебез бар. Аның кысаларында Ренат Халитов җитәкчелегендә бер концерт узачак, ул булачак программа турында фикер алышырга мине дә чакырды. Быел Мансур Мозаффаровның юбилей елы булгач, концертны аның иҗатына багышларга уйладык. Мин анда виолончелист буларак та оркестрда уйныйм. Композиторның әллә кайлардан архивлардан табылган партитуралары бар, шуларны тәртипкә китердек. Арада татар көйләренә язылган берничә увертюра бар. Аларны халык та белми, музыкантлар да. Шулай тузан җыеп ятканнар… Карап чыгып реставрацияләгәч, шаккаттык: шулкадәр югары дәрәҗәдә язылган! Дирижерлык буенча белемем булгач, беләм, күп рус композиторларының әсәрләрен уку процессында мисал итеп китерәләр, кулланалар, әйтик Глинка, Римский-Корсаковны. Бу әсәрләр исә шулардан бер тамчы да ким түгел! Бик кызыклы, профессиональ эшләнгән әсәрләр. Бу әле бер генә мисал. Глинканың «Камаринская» дигән әсәре бар, дирижерлар конкурсларында программада була ул. Мозаффаров увертюрасы бу әсәрдән күпмедер дәрәҗәдә югарырак та дип әйтер идем. Анда милли рух та бар, симфоник фикерләү дә бар. Андый мисаллар күп.

– Әсәрләр күп, талантлы яшьләр дә бар. Ә яшь буын татар музыкасы дигәндә өч ноталы эстрада концертларын гына күз алдына китерә…

– Бездә талантлы яшьләр күп. Ләкин дөнья күләмендә танылыр өчен алар чарланырга тиеш. Әгәр бездә симфоник музыка фестивальләре оештырылса, анда татар музыкасы уйналса, алар үзләренең килеп җитмәгән якларын күрерләр, үсәрләр иде. Милли оркестрыбыз юк безнең. Башкортларның андый оркестры бар һәм аның репертуарында һәрвакыт башкорт композиторларының әсәрләре уйнала. Санкт-Петербург, Мәскәү гастрольләрендә дә алар милли әсәрләрен рәхәтләнеп уйный. Ни кызганыч, бездәге дәүләт симфоник оркестры татар музыкасын уйнамый диярлек, елына бер-ике тантаналы чараны исәпкә алмасаң. Югыйсә, бу эш даими башкарылырга тиеш.

– Ильяс, үзең иҗат иткән музыканы тамашачыларга ирештерү турында уйлыйсыңмы?

– Әйе, үземнең авторлык концертларымны оештырасым килә. Хыялымда бернечә концерт бар. Киләчәккә зур хыялым – тулы канлы милли оркестр булдыру…

Эльмира СИРАҖИ.

Атнаның сәяси мизгелләре

ЮМАРТ КАСЫЙМ НИ ТЕЛИ?

Узган атнада Казахстан президенты Касым-Жомарт Токаев гаммәви мәгълүмат кырында янә активлашып алды. «Хәбәр 24» дигән дәүләт телеканалына рус телендә биргән интервьюсында ул илдәге чуалышлар вакытында мәгълүмати яктан оттыруын таныды һәм интернетны вакытлыча туктатып торуын да шуның белән аңлатты. Илдә урын алган тәртипсезлекләрне исә кабат, читтән яхшылап әзерләнгән террор операциясе, дип аңлатырга тырышты. Шуңа Токаев полициягә хәтта, кисәтүсез ут ачарга да әмер биргән. Кыскасы, җавапларның аклануга корылганлыгы күренеп тора. Аның әйтүенчә, илгә ОДКБ көчләре керер алдыннан ул Мәскәүгә берни дә вәгъдә итмәгән, элеккеге лидер Н.Назарбаев белән дә вәкаләтләр буенча бәхәс булмаган. Үзе исә Конституциядә каралган ике сроктан ары президент булып калырга җыенмавы турында да белдерә. Тик сорау туа: ни майтармакчы соң Юмарт Касыйм («Жомарт» татарча шулай әйтелә) шундый мондый гамәлләре белән? Ә ниятләре яхшы, имеш: бу вакыт эчендә ул илдә сәяси системаны һәм җәмгыятьне трансформацияләп өлгерергә җыена, парламент һәм партия системаларына кагылышлы реформалар пакетын исә быел сентябрьдә үк тә тәкъдим итәргә тели.

Гомумән алганда, Казахстандагы хәлләрне «хакимият транзиты» һәм эчке этеш-төртешләр нәтиҗәсе, дип карарга кирәктер. Күренә ки, «Назарбаев-Токаев тандемы» ышанычсыз булып чыкты. Авыру Назарбаевның БДБ лидерлары саммитында «падишаһ» катына китерелүе сәбәпләре дә бераз ачыклана төште кебек. Ә зур амбицияләр белән төзелгән ОДКБ көчләренең тормыштагы реаль функциясе бик примитив булып чыкты. Шуның белән бергә, әлеге вакыйгаларның геосәяси үлчәме дә бар кебек. Игътибарны иң элек Токаевның бу интервьюсын Кытай белән Урта Азия илләре лидерларының «Үзәк Азия - Кытай» дигән онлайн-саммиты үтүгә үк, рус телендә бирелүе җәлеп итә. Анда Токаев Казахстанның Кытайга бәйлелеге, аның белән хезмәттәшлек итәргә мәҗбүр булуы өчен дә акланды кебек. Шуның белән бергә, ул февральдә Мәскәүдә В.Путин белән озак вакытлы һәм мөһим килешүләр имзаланачагы турында белдерде.

Фоат УРАЗАЙ.

Ачык университетта – укытучыларга киңәшләр

Дөнья татар яшьләре форумы оештырган «Ачык университет» сайтында «Татар телен укытуда заманча һәм нәтиҗәле ысуллар» дип аталган курс барлыкка килде. Сайтта теркәлгәннәр аны бушлай уза ала.

Курс нотыклары октябрь-декабрь айларында Казан мэриясе һәм мәгариф идарәсе оештырган татар теле укытучылары семинарларында төшерелде. Киңрәк аудиториягә карарга мөмкинлек булсын өчен, бу чыгышлар төшерелде һәм «Ачык университет» сайтына урнаштырылды, дип аңлатты Дөнья татар яшьләре форумы җаваплы сәркатибе Зөһрә Вилданова.

Курс 3 модульгә бүленгән, һәр модульдә татар теле укытучылары, чит тел укыту тәҗрибәсе, психология һәм гомум педагогика чыгышлары бар. Темалар арасында татар телен укытуда заманча санлы ресурслар, телгә мәхәббәт уяту юллары, дәрестә уен технологияләрен куллану, тел өйрәнүгә мотивация, татар теле укытучыларына һөнәрдән ничек сүрелмәскә кебек мәсьәләләр тәкъдим ителә.

Моннан тыш укытучылар өчен курста чит илләрдә татар телен онлайн укыткан «Alima Academy» җитәкчесе Алимә Сәлахетдинова, Токио университеты аспиранты Юто Һишияма тәҗрибәләре белән уртаклашты.

Моңарчы 2019 елда «Ачык университет»та татар теле укытучылары өчен «Мөгаллим» дип аталган курс оештырылган иде инде. З.Вилданова сүзләренчә, ул платформаның иң популяр курсларның берсе булып тора.

2021 ел азагында Казан мэриясе туган телләр елы уңаеннан татар теле мөгалимнәре өчен телне һәм әдәбиятны заманча һәм нәтиҗәле укыту турында семинарлар циклын оештырган иде. Чараларда Казанның күпчелек татар теле укытучылары катнашты.

«Ачык университет» проекты Дөнья татар яшьләре форумы тарафыннан оештырыла. Ул «Акыл фабрикасы»ннан үсеп чыккан. Әлеге проект төрле темаларга татарча дәвамлы лекцияләр тәкъдим итә, аларны интернетта онлайн карап була.

Университет сайтында хәзер 18 курс узып була. Сайтта татар тарихы, заманча татар мәдәнияте, ораторлык осталыгы, акча белеме, татар дизайны, PR-менеджмент нигезләре һәм башка темаларга курслар бар.

Фәтхулла АБДУЛЛИН

Соңгы сәяхәт

(Ахыры. Башы 3 нче санда).

Ул арада Сәхби тагын телгә килде:

– Бәләкәй чакта ук синең җебегәнлегең билгеле иде инде. Аксак каз бәбкәсе күтәреп төшкән рәсемеңне күрсәм, әле дә көләсе килә. – Сүзен әйтеп бетерер-бетермәс, үзе шаркылдап көләргә тотынды: – Бот буе малай. Өстендә этинең галифе чалбары. Фуражка астыннан борыны гына күренеп тора. Ә үзе ике кулы белән каз кочаклаган.

Абыйсы ни өчен шул рәсемнән көлә соң әле? Дөрес, гаиләдә иң кечесе булгач, әнисе каз бәбкәләрен сакларга аңа куша торган иде. Арада бер аксагы иптәшләреннән калып интеккәч, Кадыйр күтәреп йөртте, саклап үстерде. Ә көз көне, бер истәлек булсын дип, шул бәбкә-казны кочаклатып, рәсемгә төшерделәр. Җә, аның ни гаебе бар инде?

Сәхби, шаркылдап туйганнан соң, кабат өстәл астына үрелде.

– Абый, җитте сиңа! Җитмешне тутырдың, һаман аракы чөмерүдән туктаганың юк.

Сәхби эре генә кыяфәттә башын чайкап алды.

– Эчсәм, мин кешенекен эчәммени? Үзем тапкан акчага эчәм.

Ул, пенсиядә булса да, ресторан гардеробында эшләвенә ишарә ясый иде.

Энесе тагын телгә килде.

– Эш кемнекен эчүдәмени? Олы кеше бит инде син!

– Минем тормышка тыкшынма, белдеңме!

Һәм үзенең сүзен куәтләгәндәй, бушаган стаканын шапылдатып өстәлгә куйды.

– Тыкшынма дисең инде, ә? – Кадыйр да кулындагы газетасын өстәлгә ташлады. – Ә син хәтерлисеңме, әтине, сабантуйда фронтташ дустын очраткач, икесенә бер чүл алып утырган өчен дә елатканчы сүктең. Ә үзегез иптәшләрегез белән аракы чөмереп, бәлеш тыгындыгыз да, Мәрфуга түтиләрнең тазын мишень итеп, пистолеттан аттыгыз.

Сәхби ярыйсы ук мәлҗери башлаган иде, битараф кына кулын селкеп куйды.

– Исең киткән икән. Тазга ату бит әле ул кеше ату түгел.

– Ә син хәтерлисеңме, таздан иләк ясагач, урманга чыгып көмеш акчаларга аттыгыз. Ә кем сурәте төшерелгән иде анда? Ә? Йә, ник дәшмисең?

Кадыйрның сүзе Сәхбине кинәттән айнытып җибәрде. Ирексездән аның иреннәре тартышып куйды. Ул урыныннан сикереп торганын үзе дә сизми калды.

– Юк! Андый хәлнең булганы юк! Булганы юк! – диде ул, тотлыга-тотлыга. Һәм ни өчендер үзе тиз генә телевизорын сүндерде. – Син авызыңны чамалап ач, малай актыгы!

Сәхби, тузынып, ишекле-түрле йөреп килгәннән соң, кабат урынына сеңде. Күзләрен кысып, сул кулы белән маңгаен ышкып алды. Ул энесен каралтырлык «фактлар» эзли иде. Әмма никадәр генә хәтерендә казынмасын, Кадыйрга яла ягарлык вакыйга исенә төшмәде.

– Ә син хәтерлисеңме биш яшькә кадәр имгәнеңне? – диде ул, аптырагач. – Сөлек кебек әнинең җелеген суырганыңны? – Һәм үзенең сүзеннән канәгать булып, имән бармагын югары күтәрде. – Әһә! Менә ни өчен озак яши алмаган, значит, безнең әни! Ничек мин моны элегрәк уйламаганмын, ә? – Кипкән бармак түбән төшкәндә бер урында дерелдәп алды. – Бер җәзасыз калдырмаган булыр идем мин сине!

– Юкны сөйләмә, зинһар! – диде Кадыйр. Хәзер аның абыйсына ачуы кабарган иде. – Бала имезгән өчен кеше гүргә керми. Ул чакта менә синең кыланышың кырга сыймады. Әнине вакытсыз кабергә тыгучы син ул, беләсең килсә. Яшәрлеге бар иде әле аның. Ә җелек тәмен синнән дә яхшы белүче юк инде ул.

– Әә-ә, акланмакчы буласыңмы? Барып чыкмас!

Кадыйр абыйсының зәһәрләнгән чыраена күз төшереп алды. Бүсер чыгарлык авыр эштә дә эшләмәде. Яшьтәшләре сугышта кан коеп йөргәндә дә, җаен табып, бармый калды. Ә барыбер, дуңгыз кылы кебек сирәк чәчләренә кырау төшкән, кайчандыр чиртсәң каны чыгарга торган битендә тирән-тирән җыерчыклар хасил булган. Алар ничектер, рәшәткәле тәрәзә сыман, күнелгә шом салып, аркылы-торкылы шакмакланып торалар иде. Әйе, ни генә димә, вакыт үзенекен итә, үзенчә талкый. Сәхбинең болай зәһәрләнүе дә хәзер инде агуын суга агызган еланның ысылдавын хәтерләтә иде. Әнисенең үлемен күз алдына китергәч, Кадыйр да кызып китте.

– Налогың түләнмәгән, дип, ятим карчыкның актык кәҗәсен алып чыктыгыз! “Халык дошманы” дип, ничаклы кешенең башын ашадыгыз! – диде ул, ярсып. – Бер гаепсез авылдашларның җанын кыюдан да кабахәтрәк тагын ни бар, аңласаң. Шуңа күрә хәзер кайтырга куркасың.

Бөкрене кабер генә төзәтә ала, диләр ич. Сәхби ык-мык килеп, акланмакчы булып маташты:

– Без үз функциябезне үтәдек. Жалоба булгач... Безгә ни... Безгә нәрсә...

– Беләм инде мин ул жалобаның ничек язылганын! Беләм! Берәрсе әзрәк бригадирга каршы әйтсә, тегесе яза да бирә. Икенче бер тинтәге көнчелектән шулай кылана. Ә сез шуны тикшереп тормыйсыз...

Сәхби борын астыннан мыгырданды.

– Бар иде инде ул контрлар. Бар иде.

Кадыйр бөкрәеп тәмәке кабызырга маташкан абыйсына, беренче кат күргәндәге сыман, сәерсенеп текәлде.

– «Бар иде» менә... «Бар иде»... Безнең җитмеш хуҗалыклы Биш Курай авылына вагоны белән китереп аударганнар иде ди сиңа ул контрларны. Заманында колхоз оештырып йөргән Мөхәммәтнур абзыйның контр дияр иденме әллә? Ә сез аны ишек ачарга чыккан җиреннән ак күлмәк-ыштан белән алып киткәнсез. Кәвешне генә булса да киимче, Сәхби энем, дип инәлеп сораган бит. Бер гөнаһсыз сабыйлар тилмереп әтисез үсте. Егерме биш яшьтә тол калган Хәкимә җиңги әле дә ирен көтә...

– Без – инструкция... – Сәхби ютәләнә буылды. Шуның өчен аның сүзе дә беразга өзелеп торды, -...буенча эшләдек.

– Ә син, абзыкаем, маташтырма! Бер гаепсез кешене алып китәргә диелгән идемени анда? Кешенең орлык бәрәңгесен алып чыгарга диелгән идемени?

– Ярар инде. Үткән-беткән. Бүгенгесе көндә мин персональный пенсионер. Так что...

Энесе аны ярты сүздә бүлде:

– Персональный?! Беләм инде мин синең ул исемне ничек алганыңны...

Бу кадәресен Сәхби көтмәгән иде.

– Ах, син, елан! Капитализм калдыгы! Төрмәдә черетәсе калган икән сине!

– Ә мин дөресен әйтәм.

– Дөреслек?.. Пычагыма кирәкме миңа ул дөреслек? дип ысылдады Сәхби, ни өчендер күзләгеен бер киеп, бер салып. – Дөреслек миңа пенсия ашатмый!

Кадыйр, башын селкеп, беркавым абыйсына карап торды. Ә бит кесәсендә партбилет йөртә югыйсә. Кайчандыр партия исеменнән сөйләп йөргәндер.

– Эх, абый, абый! Берүзеңә дүрт кыз, ә берсендә бер намус әсәре юк.

Кадыйрның бу сүзләре утка керосин сипкәндәй тәэсир итте.

– Бар, чыгып кит! Эзең булмасын! – дип кычкырды Сәхби, калтыраган тавыш белән.

Энесе дә җавапсыз калмады.

– Һәм булмас та! Туфрагыңа да килмәм!

Шуннан соң ул җәһәт кенә урыныннан сикереп торды, җилләнеп, өстенә плащын киде һәм, ишекне шапылдатып ябып, урамга – саф һавага атылды...

* * *

Икенче көнне иртән ГАИ хезмәткәрләре күрше район территориясендә машинасы белән күпердән очкан җитмеш яшьлек картны судан тартып чыгардылар. Милиционер мәетнең пинжәк кесәсендәге паспортын ачып карады. Аның «семья хәле...», «балалары...» дигән графалары бөтенләй буш иде. Үлекне моргка илткәч, туганнары яки якыннары бардыр дигән өмет белән торган урынына да, туган авылына да телеграмма суктылар.

Бераз көттереп булса да Биш Курай авылыннан «Андый бәндәне белмибез! Бездә андый кешенең булганы юк!» дигән җавап килде.

Ә ул торган шәһәрдән, көтеп-көтеп тә, бернинди хәбәр алынмады.

Тарихның бер маягы

Татар тарихын өйрәнүдә зур өлеш керткән галимнәрнең берсе, тарих фәннәре докторы, профессор, күптөрле китаплар авторы, хезмәттәшем Фәйзелхак Ислаев белән, 1998 елдан, Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү институтында озак кына еллар бергә эшләргә туры килде.

Ул тарих һәм җәмгыять белеме буенча укытучыларның квалификациясен күтәрү кафедрасы мөдире булып эшләде. Без, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы һәм лабораториясе методистлары, галимнәре үзебезнең телдә камил сөйләшүче тарихчы, ягымлы, гыйлемле остаз килүенә бик сөендек. Фәйзелхак Габделхак улы шул вакыт өчен иң катлаулы проблемаларның берсе – «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» курсын аерым фән буларак укытуның фәнни-методик яктан тәэмин итү өлкәсендә зур эш башлап җибәрде.

Казандагы төрле югары уку йорты профессорлары, Мәскәү нәшриятлары, шул исәптән коммерцияле нәшриятлар белән элемтә урнаштырып, алар аша федераль дәреслекләр авторлары катнашында иҗади очрашулар һәм фәнни-гамәли конференцияләр оештырулар, татар тарихы федераль дәреслекләрдә тиешле яктыртылу мәсьәләсе буенча авторлар белән даими эш алып барулар.... Тыңлаучылар - укытучылар белән, турыдан-туры тарихи проблемалар буенча аралашу мөмкинлеге булу да яңа эшкә чын күңелдән канатъ булып, канатланып эшләргә этәргеч биргәндер аңа. Докторлык диссертациясен 2005 елда яклаганнан соң, 2007 елның гыйнвар ахырында институтның Гыйльми советы аңа профессор дәрәҗәсен бирү документларын тикшерде. Гыйльми советы әгъзалары Фәйзелхак аганың фәнни эшчәнлеген бертавыштан хуплады, фәнни һәм педагогик казанышларына карата уңай сүзләр әйтелде. Мәскәүдә уңай карар 2007 елның 21 июнендә кабул ителде.

Шул ук елны Фәйзелхак Ислаевны «Мәгариф» журналының редакция коллегиясе составында эшләргә чакырдылар. Редколлегия составында җыйналган галимнәр, мәртәбәле укытучылар, профессиональ компетентлыкны исәпкә алып, татар телендә бердәнбер педагогик журналны заман таләпләренә җавап бирерлек итеп чыгару өчен тырышып эшләде. Бик күп тарих укытучылары белән якыннан танышу, аларга төрле мәсьәләләр буенча публикацияләр әзерләшү...

Диссертация яклаганнан соң, Ф.Ислаевка элегрәк кичектерелгән мәсьәләләре белән дә шөгыльләнергә мөмкинлек ачыла. «Оныклар үсеп килә, ә алар ата-бабалары, нәсел тамырлары белән бик кызыксынмый. Шуннан соң укытучылар белән сөйләшә башладым, балалар белән эшләргә кирәк бит, дим. Алар: «Безнең китап юк», диләр. Шуннан: «Булмаса, үзем язып бирәм, дип, тотындым бу эшкә», – дип искә төшерә галим. Ул берничә ел генеалогия мәсьәләләре буенча мәктәп өчен уку әсбабы әзерләү буенча эшли. Тарих укытучылары өчен әлеге тема буенча махсус курс та укый. Берничә тапкыр укытучыларга уку әсбабын әзерләү буенча хезмәттәшлек итү үтенече белән мөрәҗәгать итә. Ниһаять, Алсу Мортазина һәм Александр Прокофьев составында иҗади төркем оеша. Кыска гына вакыт эчендә алар Фәйзелхак ага эшләгән дәреслек буенча эш дәфтәре, укытучыга методик рекомендацияләр әзерли. Гомуми тырышлык нәтиҗәсендә «Мин һәм минем шәҗәрәм» исемле укыту-методик комплекты 2008 елның җәенә басмага әзерләнеп, рус телендә нәшер ителә. Ә татарча варианты башта тоткарлана, аннары бөтенләй басылмыйча кала. Укучылар арасында генеалогик белемнәрне популярлаштыруга Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Ялкын» журналы редакциясе, республиканың мәгариф музее белән берлектә «Гаилә елы» һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 65 еллыгына багышланган шәҗәрәләр бәйгесе үткәрү дә ярдәм итә. Казанда бу конкурсларга тантаналы рәвештә йомгак ясау катнашучылар һәм укытучылар өчен чын шәҗәрә бәйрәменә әверелә.

«Архивка кермичә дә 5 буынны табарга була, әти-әни, әби-бабаларыгыз бу эштә ярдәм итәр. Ә менә 6-7 нче буыннарны эзләргә кирәк булуы бар. Бу эштә ЗАГСка мөрәҗәгать итегез. Ул кыйммәткә төшми. Интернет аша да архивлардан табарга, электрон адрес белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Аннары, халык санын алу кәгазьләреннән эзләргә кирәк. Алар аша XVII гасырга кадәр булган мәгълүматны табарга була...», дип аңлата галим.

1990 еллар уртасында Фәйзелхак Ислаев үзе өчен бөтенләй яңа фәнни тема – татар тамгалары белән кызыксына башлый. «Архивларда XVII-XVIII гасыр чыганаклары белән эшләгәндә, мин еш кына татарлар имза урынына үз тамгаларын куйган документлар белән очраша идем. Тамгалар татар тарихчылары тарафыннан фәнни планда бөтенләй өйрәнелмәгән булып чыкты, гәрчә кайбер сюжетларны профессор Миркасыйм Госманов, Дамир Исхаков, Дамир Гарифуллин һ.б. хезмәтәндә очратырга мөмкин булса да. Мин тамгалардан торган зур коллекция җыйдым, әлеге тема белән төрле конференцияләрдә чыгыш ясый башладым, мәкаләләр әзерләдем». 2000 елда нәшер ителгән «Күктәкә тарихы» дигән китабының «Авылым тамгалары» бүлегендә ул: «Борынгы заман халык тормышында тамгалар шактый урын тотса да, әкренләп онытыла. Яшьләр тамгалар турында бөтенләй диярлек белми. Бу очраклы гына түгел, чөнки тамгалар турында гади халык кына түгел, галимнәр дә әлләни белми. Борынгы заманда төрки халыкларда тамга ыру-кабилә билгесе булган. Һәр ыру тамга белән үзенең җир биләмәләрен күрсәткән. Мондый традиция егерменче еллар башына кадәр сакланган. Авылдагы картлар сөйләвенә караганда, басудагы җиргә, әрәмәлеккә, печән чаба торган урынга тамга сала торган булганнар. Тамга агачка балта яисә пычкы ярдәмендә ясала. Җиргә көрәк белән чокып куела. Шул ук чорда мал-туарга да тамга салу гадәте сакланган. Шулай ук тамгалар элеккедән сакланган күп кенә эш коралларында да очрый. Ыру-кабилә тамгалары соңыннан шәхси тамгага әйләнгән. Татар тамгалары нәсел буенча буыннан-буынга үзгәртелмичә тапшырылган, ягъни әтисе төпчек малаена үз тамгасын калдырган. Шуңа күрә, тамга буыннан-буынга үзгәрмичә, бик озак яшәгән. Тамгаларны чагыштырып, теге яки бу нәселнең туган икәнлеген дә исбат итеп була. Тик моның өчен тамгаларның үзгәрү механизмын белергә кирәк», – дип язган иде.

Тамгаларның зур гына бер өлеше архивларда, революциягә һәм аннан соңгы чорларда авылларда җир мәсьәләсенә бәйле язма документларда күпләп сакланган. Бабаларыбыз кулланган тамгаларны искә алып, кулланып, үзебездә бер горурлык хисе кичереп, рухи байлыгыбызны барлар идек. Шул тамгаларның барын да, мөмкин булганча, татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдән җыеп, аларның бүгенге көндә таралган урыннарын билгеләп өлгерергә иде, дип, ашкынып яши эзләнүчән характерлы милләтпәрвәр аксакалыбыз. Республикабызның тарихы, язмышы, киләчәге белән янып яшәүче галим ул – Фәйзелхак Ислаев.

Сиринә ТРОФИМОВА,
филология фәннәре кандидаты.



ИСЛАЕВЛАР ШӘҖӘРӘСЕ

Төзүчеләре: Фәйзелхак һәм Азат Ислаевлар

ӘЛМӘНДӘР УЛЫНА ДА

...Әле кичә генә шикелле, әмма инде ун ел узган икән шул... 80 яшен бәйрәм иткәндә Ирек абыйның «Бабайлар чуагы» спектакленддәге төп рольләрнең берсен уйнап, алкышларга,чәчәкләргә күмелүен, егетләрчә нык басып, балкып торуын күрү – бу кичтә театрда булган һәркем өчен шатлык иде, бәйрәм иде. «Афәрин, Артист! Афәрин, Ирек абый!» – диешкән идек...

●«Беренче театр». И.Баһманов, Ш.Әсфәндиярова.

Ул әле әнә шулай уйнап-көлеп 90 ын да, 100 ен дә тутырыр кебек күренә иде... Аз да түгел, күп тә түгел – 84 нче яшендә Ирек абыйның фани дөньядагы вакыты киселде... Бернигә айлар күрәшә ул аны кисәк аяктан еккан авыру белән. Күңелен төшермәде – бәлки, сиздермәде... Утырган арбасын тәгәрәтеп театрда да йөрде. Премьера, кичәләрне калдырмады, хәтта тәнәфес вакытларында гадәттәгечә анекдотлар да сөйләп ала иде... Аны югалту барыбызга да авыр булды, ышанасы килмәде. Һаман сагындыра. Бер күрешеп сөйләшүе ничек рәхәт иде аның белән... Туган кебек иде ул һәрберебезгә... Шөкер, аның гомере үзе теләгәнчә матур, игелекле узды –үкенерлек түгел.

Кечкенә чактан ике хыял белән яшәгән Ирек абый. Берсе – хәрби диңгезче булу, икенчесе – музыкант яки җырчы... Кыскасы, үзе дә бик аңламыйча, күңеле сәнгатькә, сәхнәгә омтылган аның. Әлмәт шәһәре әле зур авыл гына чакта, 1932 елда гади колхозчы гаиләсендә алтынчы төпчек малай булып дөньяга килгән ул. Әтисе Вәли абзый һәм әнисе Фатыйма апа – җырга оста, нәфис күңелле, якты матур табигатьле, талант белән туган кешеләр булган. Балаларында белемгә, сәнгатькә мәхәббәт тәрбияли белгәннәр. Нәтиҗәдә – юрист, табибә, укытучы, финансист, нефтьче һәм артист чыга бу гаиләдән.

Оста итеп гармунда уйнаган Әнвәр абыйсыннан күреп, Ирек тә балачакта ук кулына гармун ала һәм бу музыка коралы гомер буе аның моңлы дустына, юлдашына әйләнә. Соңрак хромкада, баянда, пианино, аккордеонда да «әйттерә» башлый. Музыкаль сәләте киләчәктә аның күп кенә рольләрен бизи. Җырга осталыгы мәктәп елларында ук беленә. Беренче кат сәхнәгә чыгып башкарган җыры да гади генә көй түгел – «Эшче» операсыннан Нигъмәт ариясе! Бу инде үсмер егетнең тавышы, вокаль мөмкинлекләре турында гына түгел, аның зәвыгы, киң карашлы, затлы табигатьле булганын да сөйли. Әйе, нәкъ шулай һәм соңгы көненә кадәр әлеге асыл сыйфатлары белән үрнәк булып яшәде ул.

Ирек абыйның беренче хыялы тиз тормышка аша. Аның хәрби хезмәте Төньяк диңгез флотына туры килә һәм ул чактагы тәртип нигезендә ул өч ел эчендә офицер дәрәҗәсе дә ала. Бераз сүземне алга сикертеп әйтсәм – сәхнәдә дә хәрбиләрне күп һәм бик килештереп, яратып уйнады ул! Туган ягына кайтып (Әлмәтнең җир мае белән данланган чагы), бер ел нефтьче-оператор булып эшләгәч, ул Казанга килә һәм техник училищеда укый башлый, ике елда механик һөнәрен үзләштерә, заводка урнаша. Тагын бер ел уза. Ниһаять, икенче төп хыялны тормышка ашырыр форсат килеп чыга. Качалов исемендәге рус

●«Беренче театр». Ф.Әхтәмова, И.Баһманов.

драма театры каршында татар театры өчен укучылар җыю турындагы белдерү егетне кабат кабындыра. Соң булса да, атып калганчы, атып кал! Конкурс зур. Аның яше дә 26... Әмма имтихан алучылар – Камал театрының Шириздан Сарымсаков, Празат Исәнбәт, Габдулла Шамуков кебек атаклы осталары егеттәге талантны күрәләр. Өстәвенә тышкы кыяфәте – төз озын буй-сын, сөйкемле йөз, матур тембрлы тавыш, шәп дикция, җыр-моңга, гармунга сәләте аның сәхнә кешесе булырга тиешлеген раслап тора.

Бирегә Ирек Баһманов Наилә Гәрәева, Рәсим Сәләхов, шагыйрь булып танылачак Мансур Шиһапов белән бергә укый. Икенче курстан ук аның сәхнә тормышы башлана. 1961 елда уңыш белән театр студиясен тәмамлый. Камал театрына Мәскәүнең Щепкин театр студиясеннән зур төркем яшь артистлар кайткан чак – шуңадыр, Ирек абыйны Күчмә театрга чакыралар. Анда берничә ел эшләгәч, ул барыбер үз урынын Академия театрында таба.

Гомернең ярты гасырдан артыгы сәхнәдә, тамашачы хозурында узган, 150 ләп роль уйналган. Нинди жанр, нинди чор, нинди характер булса да, актерның диапазоны сәхнәдә яки фильмнарда тормышчан образлар иҗат итәргә мөмкинлек бирә. Һәм ничек кенә кыяфәтләрен үзгәртмәсен –табигыйлеге белән шаккатыра, сокландыра. Хәрби киемдәме, галимме, укытучы, йә профессормы, рус, татар яки башка милләтнең берәр затлы зыялысымы, ишанмы, мулламы, гади авыл кешесе, тегермәнче, көтүче, йә булмаса җилкуар, эшлексез, эчкече бер адәмме, аферистмы, яхшымы-начармы, дошманмы-дусмы – артист һәрберсенә ышандырырлык үзенчәлекләр таба, тышкы килеш-килбәте дә, тавышы да, адымы-хәрәкәте дә нәкъ шул образга гына хас килеп чыга. Өстәвенә, алар барысы да Ирек абыйча сөйкемлеләнгән дә югалтмый. Халкыбызның бик яраткан, хөрмәтле артистына әйләнә ул. Үз гаиләсендә генә түгел, Театр дигән гаиләдә дә – түр башындагы кадерле кеше иде. Яшьләре дә, яшьтәшләре дә зур ихтирам белән карый иде аңа. Мәгънәле, белемле, итагатьле, олыны – олы,кечене – кече итә белә торган, сабыр, тыныч холыклы, үзе бик нечкә хисле, үзе җор телле, юморга бай бу талантлы артист белән аралашсаң – күңелләр җылынып, дөнья яктырып китә иде. Кешеләрне яратучы, масаюны белми торган һәм үзе дә мактанчыкларны сөйми торган бер зат иде Ирек абый... Әйе, үзең киткәннән соң, әнә шулай матур сыйфатлар белән искә алулары өчен, ничек мәгънәле яшәргә кирәк!..

Бер өлкән артистның юбилей кичәсендә атаклы режиссер Марсель Сәлимҗанов «Бу яшькә җитү – ул үзе бер батырлык» дигән иде. «Ни өчен Ходай Тәгалә биргән гомер батырлыкка тиң икән» дип уйлаганым истә...

Ә бит чынлап та, бирелгән гомерне төрлечә уздырырга мөмкин. Ирек абый кебек 80 яшенә кадәр сәхнәдә булу өчен, образлар тудыру өчен үзеңә, сайлаган юлыңа никадәр таләпчәнлек, җаваплылык, тырышлык булу тиеш. Халыкта «Холык – икенче бәхет» дигән сүз дә бар. Әнә шул холык-фигылеңне шушы юнәлештә җигәр, үзгәртер өчен дә ихтыяр көче, максатчанлык кирәк һәм үз мин-минлегеңне, нәфесләрне җиңә белү дә мөһим. Әти-әниең, якыннарың, гаиләң, якташларың алдында – аларның йөзләренә кызыллык китермичә

●«Кылый Кирам балдагы». И.Мәсгуди, И.Баһманов.

●«Әлдермештән Әлмәндәр».

90 ЕЛ ТУЛДЫ

●«Әлдермештән Әлмәндәр». И.Баһманов, Ш.Биктимеров.

●«Өзелгән өмет».

●«Шаулыйлар дулкыннар».

тормыш итүне дә беренче урынга куйсаң... Әйе, бөтенесе бергә бу – нәкъ менә батырлыкка тиңдер...

Рухи дөньясы бик бай иде Ирек Баһманның. Милләтнең зыялылары, шагыйрьләр, язучылар арасында дуслары бик күп иде. Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов моңнарына мөкиббән китеп, алар башкарган халык җырларында тәрбияләнгән Ирек ага Хәйдәр Бигичев, Илһам Шакиров тавышларына гашыйк иде. Әмирхан Еники әсәрләрен гомер буе яратып укый иде. Мөхәммәт Мәһдиев белән – язмышларында да уртаклык булгангадыр, бик якыннан аралашкан алар. Икесе дә диңгезче-моряк булган, икесенең дә этиләре шәхес культы чорында кулга алынган...

Кечкенә Ирекнең хәтеренә уеп кергән бер шомлы күренеш гомер буе күз алдында торды – Әлмәт төрмәсендә этисе белән очрашу... Йозаклы, тимер рәшәткәле ишекләрнең шалтыр-шолтыр ачылулары, этисенең борчулы йөзе, акрын тавышы... Аннан аны Бөгелмәгә, аннан Казан төрмәсенә алып китәләр. Тикшерәләр... Дәүләткә терлек тапшыру оешмасында эшли башлаган Вәли абзыйны, кайбер малларның үлемендә гаепләмәкче булалар – «илгә корткычлык», янәсе. Шөкер, гаеп исбатланмый, хөкемгә тартырлык дәлилләр табылмый, гаилә кара таптан котылып кала. Бу вакытта Казанда судья хезмәтен башлаган олы кызларының да тырышлыгы бушка китми – Ирек этиле гаиләдә үсә.

Мөхәммәт абый үзенең әсәрләрен радио аша укыр өчен дә гел Ирек абыйга биргән. Ирек Баһман укуында Татарстан радиосының алтын фондында бик күп язмалар саклана. Менә дигән нәфис сүз остасы да иде ул. Ана телебезне бөтен нечкәлекләре белән шәп белүче. (Ул бит чын милләтпәрвәр, бик татар җанлы кеше иде.) Шигъри әсәр булсын яки проза –артист жанрны шулкадәр дөрес тоеп, эчтәлекне үз йөрәгеннән уздырып, тавышының төрле бай төсмерләре белән гаять хисле итеп җиткерә ки, син ирексездән шул мохиттә, шул каһарман кичерешләре белән яши башлыйсың – көләсең, елыйсың...

Бер генә мисал. Себер лагерьларында нахакка газап чиккән язучы Ибраһим Сәлаховның «Колыма хикәяләре» исемле китабыннан «Чегән кызы» дигән өзекне Ирек абый башкаруында ничә тыңласам да, күз яшьләренә тыгылам. Радио режиссерлары андый мизгелләрдә артистның үзенең дә күзләре дымлануын сизә, туктап калганын да хәтерлиләр... Ә иртән инде «Хәерле иртә» тапшыруында ул шаярта, көлдерә – бу тапшыруның дистә еллар алыштыргысыз алып баручысы булды ул.

Театрда гына түгел, Ирек Баһманов әнә шулай радио, телевидение аша һәм сәхнәләрдән әдәби кичәләрдә милли әдәбиятыбызның гүзәл үрнәкләрен тамашачыларга ирештерде. Студентларны – булачак артистларны сәхнә теле фәне серләренә өйрәтте.

Мин үзем Ирек абыйның яшьлектә күргән ике ролен сагынып искә алам. «Зөбәйдә – адәм баласы» спектаклендә ул – Зөбәйдәнең абыйсы Фәрит; вата-җимерә татарча сөйләшеп, үз рәхәтен генә уйлап йөргән җилбәзәк, заманча егет. Үзе көлке, үзе бер мескен. «Хуш, Назлыгөл»дә исә үзен үлемгә дучар иту бәрабәренә пассажирлар пароходын радиация дулкыныннан саклап калган хәрби диңгезче, көчле ихтыярлы, нык рухлы Газиз. Инде соңгы көннәрендә аяныч язмышлы Назлыгөлне очратып, холкы сына башлаган, тормышта адашкан яшь хатынга ул үзенең ихлас кешелеклелеге белән дөрес кыйбланы табарга ярдәм итеп өлгерә. Бу хушлашу шундый сагышлы. Япь-яшь яхшы кешенең котылгысыз үлемгә китеп баруы – бик тә ачындыра... Әмма Газиз кебекләрнең булуы күңелне сафландыра, изгелеккә өнди иде. Артистның сәхнәдә дөрес яшәве, талантының көче белән генә ирешеп була мондый нәтиҗәгә. Хәрби киемдәге мәһабәт һәм мәхәббәтле Газиз-Ирек Назлыгөлне генә түгел, тамаша залындагы һәрбер хатын-кызны гашыйк иткәндер... Ирек абый үзе дә бу рольләрен һәм шуңа өстәп «Әни килде» спектаклендәге Ананың сугыштан аяксыз кайткан улы Инсафны, шулай ук сугышның исән корбаны авыру Искәндәрне бик рәхәтләнеп яратып уйнаган.

Әйе, 30 ел «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклендә Искәндәр булып, тамашачының аеруча мәхәббәтен яулады ул. Көчкә генә бөкрәеп йөргән, әкрен генә өзек-өзек сөйләшкән «карт»ны чынлап та шундый хәлдәдер дип уйлап, кызганып, хәтта кайбер ерак төбәкләрдә «үзем тәрбиягә алам» дип сәхнә артына керүчеләр дә була. Ә анда төз гәүдәле, шаян телле Баһман басып тора!

Артистның иҗат коесы саегуны белми торган тирән иде. Соңгы елына кадәр актив яшәде. «Өзелгән өмет» (М.Горький), «Ханума» (А.Цагарели), «Арбалы хатыннар» (З.Зәйнуллин) спектакльләрендә төрле пландагы кызыклы рольләр уйнады. Лаеклы ялга чыгу дигәнне аңларга да теләмәде –театрдан башка ул үзен күз алдына да китерә алмый иде. Шундый ук олы мәхәббәт белән ул гаиләсен яратты. Аның гаиләсе менә дигән иде. Табибә Рәшидә апа белән асыл балалар – эти-әни дип өзелеп торган егет белән кыз үстерделәр.

Тик менә күпләрне сокландырып гел бергә театр-концертларга йөргән хәләле, бик сөйкемле Рәшидәсе иртәрәк дөнья куйды. Башта ул күрү сәләтен югалтты. Кызы Нәргис белән бала баккан кебек карады аны Ирек абый. Ике дистә елдан артык җитәкләп, кадерләп йөртте сөекле хатынын... Һәр яңа спектакльгә, кичәләргә алып килде. Белмим, андыйлар бар микән тагын?.. Ни кызганыч, Рәшидәсе үзе белән гүя тормышның бөтен ямен, кызыгын алып китте... «Кечкенә оныгым Әминәгә юанып яшим һәм театр яшәтә», – ди иде...

Мин Ирек абый белән бер әңгәмә вакытында:

– Сез озак еллар театрның партия оешмасын җитәкләгән кеше идегез. (Ул чакта бу урынга тискәре яклары, начар гадәтләре булмаган иң хөрмәтле кешене генә сайлыйлар иде.) Мәчеткә йөрүчеләрне дә яратмый иде Совет власте, диңгә, теге дөньяга да ышанмыйлар иде, – дип, аның бүгенге заманга мөнәсәбәтен сорадым.

– Мин бөтен барлыгым белән теге заман кешесе инде. Без кешелекле булып үскәнбез. Үзең беләсең, мин начар бәндә түгел. Кеше рәнҗеткән юк, дөрес яшим кебек. Әмма, нишлисең, атеизм көчле вакытта формалаштык. Тиз генә үземне «үзгәртеп кора» алмыйм. Ничек яшәсәм, шулай дәвам итәм.

Минемчә, якты дөньяда яшәү – иң зур бәхет. Үлгәч, югала инде кеше... Шуңа күрә матур яшәргә кирәк. Үкенерлек булмасын. Гомер бик кыска икән... «Сизми калдым,белми калдым,яшь гомернең узганын...»

Ирек абый, Сез матур яшәдегез. Һәм Сезнең кебекләр, аларның эше, иҗаты югалмый. Сез безнең хәтердә һәм Сез – тарихта...

Луара ШАКИРҖАН,
Татарстанның халык артисты.

●«Хуш, Назлыгөл». Г.Исәнгулова, И. Баһманов.

●«Канлы күләгәләр». Ә.Шакир, И. Баһманов.

Коронавирус чигенергә уйламый

2021 елда Россиядә COVID-19 йоктырган ярты миллионнан артык кеше үлгән. Бу хакта Росстат хәбәр итте . Федераль хезмәтнең рәсми сайтында әйтелгәнчә, коронавирус 390 мең кешенең төп үлем сәбәбе дип карала.

Былтыр Татарстанда 10 433 кешенең үлемендә төп сәбәп коронавирус булган диелә. Үлемнәр саны Татарстанның коронавирус белән көрәш штабы китергән рәсми саннарыннан нык аерыла. Соңгы мәгълүматка күрә бөтен пандемия дәвамында республикада COVID-19дан 1 576 кеше үлгән.

Татарстанда иң күп үлемнәр саны октябрь (1870) һәм ноябрь (2720) айларына туры килә. Декабрьдә үлгән 616 кеше коронавируслы булган. Татарстан штабы декабрь аенда көндәлек бирелеп барган мәгълүматка караганда, бу айда рәсми рәвештә теркәлгән ковидтан 176 кеше бакыйлыкка күчкән.

Россиядә декабрьдә COVID-19 аркасында 44390 кеше җан тәслим кылган, тагын 4 меңнән артык кешенең дә төп үлем сәбәбе тәҗлы вирус булырга мөмкин. Чагыштыру өчен бер сан: 2019 ел хисабы буенча, Татарстанның Мамадыш районында 42 мең кеше яши.

Росстат хәбәр иткәнчә, 2021 елда Россиядә 400 мең кешенең үлемендә төп сәбәп булып коронавирус торган. Тагын 50 меңнән артык авыруда коронавирус үлемгә китергән дип санала ала. COVID-19 үлемгә илткән сәбәпләрнең берсе булырга мөмкин дигән саннарны исәпләгәндә, гомере өзелгән кешеләрнең саны 517 мең кешегә җитә.

Бу саннар пандемиянең беренче елыннан 3,2 тапкырга күбрәк. 2020 елда 163 мең кешенең (144 меңендә коронавирус төп сәбәп) үлеме турында хәбәр иткәннәр иде. Россиядә коронавирус тарала башлаудан алып барлыгы 681 мең кешенең гомере өзелгән. Россиянең оператив штабы пандемия дәвамында коронавирус йоктырган 329 мең кеше үлүе турында хәбәр итте.

2021 елда Россиядә барлыгы 2,4 млн кеше үлгән. Бу, 2020 ел белән чагыштырганда, 15 процентка күбрәк. Халыкның табигый кимүе 1,04 миллион булган.

2022 елның беренче гыйварына караганда Россиядә 145,478 миллион кеше яши.

Россиядә гыйнварның соңгы көннәрендә коронавирус йоктыручылар саны күрсәткече иң югары дәрәҗәгә җитте.

Күк гөмбәзен

Ике атна чамасы элек кенә арабыздан яраткан язучыбыз Заһид Мәхмүди китеп барды. Әлеге истәлек әдип үзе исән чакта ук язылса да, газетада нәшер ителергә өлгермәгән иде.

Заһид Мәхмүди хатыны Рәшидә белән.

Үз йортында яшәү! Кем-кем, Заһид Мәхмүди инде моның тәмен яхшы белә. Күпләребез бер тулай торактан икенчесенә күчеп интеккән вакытта, кеше фатирында торганда, бәхетлерәкләр юка стеналы – күршенең кырынганы ишетелеп тора! – фатирларга тиенгәндә, ул Казанның тарихи өлешендә, Ерганак урамындагы (ул инде, әлбәттә, рәсми рәвештә улица Овражная дип атала иде) үз йортында яшәде.

Йорт борынгы, теге гасыр башында ук салынган; Заһид аның беренче катын гына били – ләкин мәйдан зур – урыс куписларынча иркенлек: олы залы, аш бүлмәсе, тагын бер-ике бүлмә – бу безнең төшкә дә кермәслек байлык. Ә бакчасы! Ул Ерганакның яры буйлап өскә менеп китә, ә өстә исә чып-чын авыл мунчасы. Язларын алмагачлар, чияләр ап-ак күбеккә баткандай чәчәккә күмелеп утыра, кайдандыр сирень, шомырт исе борынны ярып керә, башны әйләндерә, һи-и, яши белә инде Кукмара егете! Кайдан башына килгән бу бакчалы йортны сатып алырга? Дөрес, мондагы бәхетнең ахыры күренеп тора – Казанда иске йортларга каршы сугыш башланган иде инде. Шуңа күрә ул бәхеттән без тулысынча файдаланып калырга тырыштык. Җае чыккан саен әлеге кунакчыл йортка киләбез. Кирәкле кишер яфраклары... Әнә алар бакчада күпме! Әмма Заһидның хатыны Рәшидә ханым да киң күңелле хуҗабикә – аякта нык басып торсаң, кире куып җибәрми.

Хәер, мин үзем гадәттә Заһид белән бергә үк кайта идем.

Без дигәнем шул әлеге дә баягы яшь каләм әһелләре. Безнең буын. Мөгаен, "сиксән бишенче ел буыны" дип әйтергә буладыр. Әлеге елны Империя башына, маразматик картлардан соң, чагыштырмача яшь Горбачев менде һәм халыкка иркен сулыш вәгъдә итте. Ә без вәгъдәләргә ышана торган халык. Ләкин гадәттәгечә буш вәгъдә булып чыкмады ул. Ирек һавасын бераз сулап калдык. Иркен сулыш! Әйе, без шул елның җимешләре. "Иделчеләр" дип атасаң да була безне. Барыбыз да диярлек 1989 елда чыга башлаган "Идел" журналында колач җәеп йөзүчеләр. Кайберәүләр исә беренче чирканчыкны да шунда алды. Заһид Мәхмүдинең дә чып-чынлап әдәбиятка аяк басуы шушы журналда булды.Ул үзе дә моны таный, ул вакыттагы баш мөхәррирebез Фәиз Зөлкарнәйгә әле дә рәхмәтле.

Заһид "Идел" редакциясенә еш керә иде. Аның өе безнең редакция урнашкан Мөштәри урамындагы 14 нче йортка якын гына. "Җавап визитлары"на да гаҗәпләнәсе түгел. Урам башындагы элекке Габитовлар йортының икенче катында Нияз Акмал яши. Аңардан кул сузымы гына арада Зиннур Хөснияр... Шаулап тора иде бу төбәк. Заһид Мәхмүдинең тавышы Акмалныкын гына баса алмагандыр. Хәер, ул вакытта барыбызның да тавышы ерактан ишетелә иде.

Шулай бер көнне, җәйге тымызык кичтә, редакциянең балконлы бүлмәсендә Заһид белән сөйләшеп утырабыз. Ул балкон үзе үк шул заманның әдәбият тарихында калырлык. Балкон уртасындагы иске түгәрәк өстәл тирәсендә ("Идел" чыга башлагач, без аны партия өлкә комитетының амбарыннан шундый иске-москы җиһазлар белән бергә алып кайткан идек) кемнәр генә җыелмады, нинди генә сүзләр яңгырамады, нинди генә сюжетлар борын төртмәде. Балкон төбендәге кычыткannар, әрекмәннәр дә якындагы кардәшләреннән берничә башка югарырак үсә иде, әллә инде Равил Фәйзуллинның җырлавын тыңлар өчен шулай балконга таба сузылганнар? Хәер, аларны сугарып, биек булып үсүләренә барыбызның да өлеше тигәндер. Ул чакта барыбыз да җырларга ярата идек. Арада бит әле чын җырчылар да бар. Хәтта опера җырчылары! Рафаэль Сәхәби, Мөнир Якуповлар бездә еш кунак иде.

Заһид, гадәтенчә, киләчәктә язачак әсәренең эчтәлеген сөйли. "Төнге өчтә кемнеңдер тәрәзә шакуына уянып китәм, бармаклары озы-ын, кем булыр бу?" – Тик аның кемме, нәрсәме булуын белергә язмаган икән – әлегә кадәр сер булып калды! – ишектән кыска гына буйлы, тулырак гәүдәле, иңенә олы спорт сумкасы аскан пеләш бер кеше килеп керде. Башта шакыгандыр инде ул, әлбәттә. Ишек иягенә... Чөнки безнең ишек һәрвакыт ачык була иде. Адәм үзе Кавказ кешесенә охшаган, бераз яһүд чалымы да бар кебек. Ачык чырай белән каршы алдык кунакны. Өченче бит! Разил Вәлиев булса, "өченче дурәк!" дияр иде. Ләкин кунак безгә кушылырга ашыкмады. Ул Мәскәүдә нәшер ителә торган "Дружба народов" журналының баш редакторы Александр Эбанаидзе икән, язучылар берлеге җитәкчеләрен эзләп килгән, ләкин җитәкчеләр урыннарында юк, йә берәр очрашуга, йә, кич җитүен исәпкә алсаң, өйләренә кайтып киткәннәр. Эбаноидзе инде шуннан соң тавышлар ишетелгән якка килгән, табигый.

Ул вакытта мин "Дружба народов" журналын энәсеннән җебенә кадәр укып бара идем, бигрәк тә Лев Анненский мәкаләләре ошый иде (соңрак аның белән дә танышырга туры килде), шуңа сүз учагы кабынып китәр өчен, артык чыра кирәкмәде. Үзенең "Имеретинча өйләнешү" романын да искә алгач, гөрҗи тәмам йомшарды (әсәрен мактаганга кайсы гына язучы битараф кала!), зур сумкасын иңеннән салып, безнең ярлы гына табын тирәсенә чүмәште. Аның татар язучылары белән хезмәттәшлек итәргә исәбе бар икән, шул нигездә безнең хөкүмәттән матди ярдәм булмасмы, дип тә өметләнә. Татарстанда абунәчеләрне арттыру теләге дә бар. Ике меңенче еллар башы бу, ун еллар элгәре генә берничә миллионлап таралган Мәскәү журналларының тиражы бер-ике меңгә калган, башыңны Казан кирмәненең ташына да орырсың, билләһи. Безнең "Казан утлары" ул вакытта алардан дүрт-биш мәртәбә күбрәк чыга иде.

Без Заһид белән бер-беребезгә карашып алдык. Сүзсез генә аңлаштык, әлбәттә: мондый кадерле кунакны редакциядәге каты-коты табында гына сыйларга ярамый, ул бит безнең әдәбиятны (билгеле, иң элек үз әсәрләребез күз алдына килде) дөньякүләм мәйданга чыгарырга казганып йөри! Гөрҗиләр үзләре андый кунакны тау түбәсенә күтәреп менәр иде, кунакчыллыкта даннары чыккан. Равил Фәйзуллин кебек "Аһ, тау юклыклар!" – дип уфтанырсың да. Хәер, тавы булмаса да, татар

тырный кемдер...

да бөтенләй төшеп калган халык түгел, без дә кунакчыл бит, чурту-матыр. Әнә өлкәннәребез дә яза: соңгы күлмәген сатса саткан татар, кунакны коры җибәрмәгән. Күлмәк бәясе генә сый сыеграк булгандыр инде анысы, әмма бит ихластан! Сыйларга кирәк гөрҗине аяктан екканчы, Мәскәүдә генә түгел, Грузиядә дә шаккатып сөйләрлек булсын. Кесә саерак анысы, тик бит Заһидның гөлбакчага күмелеп утырган йорты янәшәдә генә! Анда киң күңелле Рәшидә ханым ничек тә татар йөзенә кызыллык китермәс әле.

– Заһид Мәхмүди морза токымыннан, – дидем мин, – Казанда бабаларыннан калган үз йорты белән тора. Бәлки, вакытыгыз булса, шуның бакчасына барып утырырбыз, сөйләшсәс сүзләр күп...

Борынгы морзалардан калган йорт Эбаноидзены кызыксындырды.

Сынап Заһидка да карап алды. Заһидның чырае ким-хур булырлык түгел, ләкин татар аксөягенең токымы дип тә булмый, ул күбрәк чегән баронына охшап тора шикелле: төтенләп торган чем кара бөдрә чәч, чөенке ияк, ярый әле кайчандыр Куликово сугышыннан чыккандай, маңгаенда сыңар җөй бар. Беребез дә татар морзасын күреп үсмәгән, Эбаноидзе да үз казанына сыймыйча кайнап утырган Мәхмүдинең морза булуына ышанды.

Киттек өчәүләп Ерганак урамына. Кояш инде баеган иде. Тымызык кич. Әле караңгы төшеп җитмәгән. Александр Луарсабовичка Казанның әлеге төбәге турында сөйләп барам, әнә Ульяновлар яшәгән йорт, әнә тегендә яшь Пешков яшәгән, ә сез беләсезме аның татарлар турында ниләр язганын? Җанын сафландырыр өчен, ул Татар бистәсенә китә торган булган. Эбаноидзеның нечкә иренен елмаю пәрәвезе куна. Елмая, генацвале; тиздән борынгы морзалар яшәгән тияктә үзенең дә җаны сафланачагына, өстеннән Мәскәүнең елтыр чуклары, вак мәшәкатьләре коелып калачагына өметләнә бугай. Заһид йорты, әлбәттә, инкыйлабка кадәрге шәһәрнең урыс ягында – өстә, корыда, саф һавалы якта урнашкан, Казан алынганнан соң монда татарның эзе дә булмагандыр; тик бит анарчы, аңарчы... Шәп җирләр ул чакта да буш ятмаган, билгеле. Шулай булгач, Эбаноидзены алгысыткан сүзләребездә бер кәррә дә ялган юк чынлыкта, шуңа да Заһид инде борынгы морза бабасының революциядән соңгы фаҗигале язмышы турында җан өшеткеч хикәятен сөйләп бетергәндә, минем дә керфекләрем яшькә чыланган иде.

Нишләптер безне Рәшидә бик төксе каршылады. Заһид аш булмәсендә аңа тиз генә нидер аңлатты, "Мәскәү журналы..." дип кайнар пышылдаганын гына ишетеп калдым, кәгазь акча кыштырдаганы да колакка чалынды. Кибет янәшәдә, тиздән өстәлдә кыйммәтле француз шәрабы затлы шешәдә шәфәкъ яктысыдай ымсындырып утыра иде инде. Тик Александр Луарсабович аңардан катгый баш тартты, мондый эчемлекләрдән тәмам гарык булып килгәнме соң... Шулай да безнең татар әдәбияты турында һаваланып сөйләгәнне шактый исе китеп тыңлады тагын. Табын мул иде, Рәшидә кунакларны сыйлый белә. Тансык кунак киткәч тә, озак сөйләшеп утырдык әле. Һи-и... яшь бит әле без, дөнья үзе, җәйрәп, аяк астында ята. Таң атар алдыннан гына шәмәхә томанны ерып мин өйгә кайтып киттем.

Атна-ун көн үткәч, Мәхмүди миңа чылтырата, сәламләшеп тә тормыйча: "Беләсеңме, мин кайда?" – ди. Әллә Кукмарага кайтып киткән инде... "Переделкинода мин! Эбаноидзеның дачасында!" Ышанырлык та түгел, ышанмаска да сәбәп юк. Бәлки Мәскәү-грузин язучысының татар морзасын үз өендә кунак итәсе килгәндер. Кунак ашы – кара-каршы, диләр бит бездә. Гөрҗиләр дә үзләрен бик кәттә кунакчыл дип мактый, булыр да! "Саша бик шәп кинорежиссер тапкан, минем "Өче балан" буенча кино төшерергә йөрибез!" – диде дә, Мәхмүдинең тавышы өзелде. Оһо! Эбаноидзега Саша дип кенә җиппәрә бу!

Әле дә шикләнәм, булдымы ул шул чакта Переделкинода, юкмы? Булмаса да, сүз юк. Без барыбыз да күпмедер дәрәҗәдә Мөдәррис Әгъләм шәкертләре. Шул вакытта ук нәфис фильмнар төшерү хыялы белән яшәгән икән Мәхмүди, еллар узгач, бер-бер артлы фильмнары экранга чыга башлады ("Мәхмүди-фильм" киностудиясе!), бу эшкә улы Фәнисне дә җәлеп итте. "Өче балан" бәяненә нигезләнеп төшерелгән "Җәза" нәфис фильмын барыбыз да сөенеп карадык. Анда ул, бер житди генә роль биреп, мәрхүм язучыбыз Фәнзаман Батталның кыяфәтен дә озакка гәүдәләндереп калдырды.

Ерганактагы йортны җимерделәр. Мәхмүдиләргә, кварталдан булса кирәк, фатир бирделәр. Анда кунакка йөреп булмады, фатир инде һәркайсыбызда бар, аның белән генә ис китәреп булмый. Заһид белән дә күрешүләр сирәгәйде. Нишләп ята икән ул яңа фатирда? Ятар, хәзер! Бераздан ишеттек –туган төягенә кайтып киткән икән ул, фермер булган, мал-туар үрчетә, диделәр. Күпмедер вакыт үткәч, авыл мунчасы кадәр кара машинага утырып, үзе дә килеп чыкты. Бик вәкарь белән төште машинадан... Менә нинди була ул татар язучысы!

Соңыннан безнең халык арасында сүз таралды, имеш, иске йортын сүткәндә Заһид яшерелгән хәзинә тапкан икән дә шуңа кинәт баеп киткән. Һич шикләнмим, бу гайбәтне ул үзе үк чыгаргандыр әле. Хәзинәне исә ул туган ягында тапты, минемчә. Кул көче белән, акыл җегәрен кушып...

Менә берзаман Казанга хәвефле хәбәр килеп ирешә: Заһидның башына ишәк типкән!

Аңарчы да аның туган ягыннан хәбәрләр гел килә торды: әле Заһид яңа газета чыгара башлаган; әле кайдандыр чит илдән өр-яңа заманча басмаханә кайтарткан, китаплар нәшер итә; әле ул яңа фильм төшергән. Кайчагында Австралия көнгерәсенең эшкәртелгән тиресеннән тегелгән эшләпәсен киеп ул телевизор экранында да күренеп ала, татарларны күп хатын алырга өнди, милләт язмышы өчен борчылуы – балалар аз булу аркасында мәктәпләр ябыла бит! Бөтен тапшыруда ул нәкъ Америка киноларындагы "кыргый мәгъриб" ковбое! ат көтүен каядыр куа; әле зур гәүдәле дөянең тамак астын кашып тора! әле ишәкләр белән мәш килә. Ул асраган сарыкларның саны өч йөзгә дә житкән дип сөйләделәр. Имеш, ара-тирә килеп чыккан Казан кунакларын шаккатырып, шунда ук көтүдән берсен алып суя да учак ягып казан аса икән! Булса да булыр, киң күңелле иде ул яшьтән үк. Аның хуҗалыгы тирәсендә гел бала-чага кайнаша, дип тә сүз житкерделәр. Монысына инде безнең "Гаилә һәм мәктәп" редакциясенең (мин шунда дүрт ай баш мөхәррир булып эшләп алган идем) колагы торды: яшь буынга менә дигән тәрбия бит бу! Җанварлар арасында үскән балалар миһербанлы була, дип журналда әледән-әле киңәшләре белән сөендерүче психолог туташ та утка чыбык өстәгәч, без инде болай да, Заһидның башына ишәк типмәсә дә, аның тәрбия өлкәсендәге уңышлары турында укучыларыбызга житкерергә уйлаган идек. Һәм менә сиңа мә! Шундый хәбәр...

Тик укучыны тынычландырырга ашыгам – Заһид безне исән-сау, дүрт саны да төгәл килеш каршы алды. Элеккечә хырхылдап көлде дә әле бер сәбәпсез. Ике дөясе, өч ишәге дә берни булмагандай утлап йөри, бихисап сарыклары чемчения, буаз биясе исә пошкырып сәлам бирде. Заһид үзе яңа фильм төшерергә әзерләнә икән. Анда гаилә тәрбиясенә багышланган тема кызыл җеп булып сузылачак, дип ышандырды. Безгә бераз сынап карап торганнан соң, мәктәп тормышы да бер эпизодны тәшкил итәчәк, дип томанлы гына вәгъдә бирде. Рәшидә ханым, башын селкеп, аны җөпләде.

Заһид Мәхмүди янынан күтәренке күңел белән, авылның киләчәге ышанычлы кулларда булуына инанып, Казанга кузгалдык. Саубуллашыр алдыннан аның маңгаена күзем төште. Маңгаенда чыннан да җөй бар иде Заһидның. Тик ул миңа таныш әллә кайчангы иске җөй иде.

"Язасыңмы соң?" – дип сорадым мин аерылып киткәндә. "Менә сөйлим әле, – дип, мине ул гадәтенчә читкәрәк тартты. – "Әтәчкә авызлык" дигән бер шәп әйбер! Мондый нәрсәне әле беркемнең язганы юк. Берәү, авылга кайтып киткәч, кошчылык белән шөгыльләнергә ниятли. Шуннан соң..." "Булды, булды, – дидем мин, котым алынып. – Сөйли күрмә, бир язганыңны, укырмын". Заһид сүлпән генә кулын селтәде: "Язылмаган әле ул. Тик шундый сюжет, малай, драма язып була. Мин аны Данил Салиховка бүләк иттем". "Нигә?" – дип сорадым мин, аптырап. "Шәп малай бит!"

Моңа ни әйтәсең? Юмарт кеше ул Заһид Мәхмүди. Минем дә күңелем булсын, диптер инде, тизрәк әйтергә ашыкты: "Шигырь китте бит әле минем соңгы вакытта, буасы ерылды". Заһидның шагыйрь дә икәнен мин, әлбәттә, белә идем. Ул үзенең нәни генә эскизларын да (үзе аларны "мәхмүдиләр" дип атый) рифмалы проза белән яза. Шуларның берсен монда да күчереп үтәсем килә: "Яңгыр ява тышта. Күк гөмбәзен тырный кемдер. Нинди үпкәсе бар аның? Дулый, шаша ни өчендер". "Әпипәгә бии тамчылар, бии халык, бии шагыйрь: "Бас, кызым, Әпипә, бие гел син безнеңчә!" Кемнәр, милләт, сине биетә? Кемнәр камыт сиңа киертә? Һәр тарафта – киртә. Әллә язмыш, әллә күрмеш йөртә..."

Моңа өстәп ни әйтәсең?

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА.
Июль, 2020.

Ислам юбилеена – аракы тотып?..

Гаҗәп хәлләр булып ята Татарстанда! Мөфтиләр Ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгында баш булу өчен тарткалашып ятканда, татар түрәләре бәйрәмгә үзенчәлекле бүләк әзерләп куйган. Шушы олуг юбилей «хөрмәтенә», Татарстанның һәр авылында аракы кибете ачылырга тиеш икән! «Татарстан вице-премьеры Рөстәм Нигъмәтуллин авылларда кибетләр саны азаймасын һәм республикада җитештерелгән исерткеч эчемлекләрне сату кимемәсен өчен, район башлыкларын «бөтен көчне куярга» өндәгән», – дигән хәбәр укыдым.

Эш харап – былтыр Татарстанда аракы сату нык кимегән, «Татспиртпром»ныкын бөтенләй аз алалар икән. Түрәләрнең әйтүе буенча, моңа авыллар гаепле, кибетләре азайган, ди. Шуннан чыгып, Татарстан түрәләре «зур булмаган авылларда республика аракысын сату өчен махсус кибетләр ачылачак», – дигән карарга килә. Ягъни хәтта кечкенә авылларда да махсус кибетләр ачып, Татарстан аракысын лыкынганчы сатачаклар икән...

Нинди мәгънәсезлек һәм корткычлык бу?! Халык аз эчә башлаганга кайгырырга түгел, сөенергә кирәк, чөнки милләтнең яртысы инде болай да эчеп эштән чыкты. Күпме затлы кешеләр, талант ияләре эчеп харап булды, күпме гаиләләр таркалды, балалар ятим калды, рәтле тормыш күрмәде. Хәзер кеше шуны аңлый башлады, кайсы дин сәбәпле, кайсы тәртипле тормыш алып бару хакына эчүен ташлады. Шушы хәл Татарстан түрәләрен кара кайгыга салган икән, халыкны яңадан сәрхуш ясау өчен, юлларын эзли башлаганнар. Һәм тапканнар: һәр авыл саен хәмер кибете ачарга! Ипи кибете яисә ризык, көн дә кирәкле тауар түгел, аракы кибете җитми икән авылларга! Ә ул бичара авылларның күпчелеге татар авыллары бит! Милләтнең карап торган нигезе, кайтып сыену урыны! Хәзер шуларны аракы сазлыгына әйләндерергә җыеналармы? Акча хакына авыллардагы соңгы татарлардан алкаш ясыйлармы?!

Нинди икейөзле син, татар түрәсе! Түбәтәй киеп, «Ислам динен кабул итүебезгә 1100 ел», – дип суфыйланып йөрисең. Инде бөтен Татарстанны дуңгыз фермалары басты, хәзер шуңа аракы да өстәлсә, безгә пандемия дә кирәкми, халык аягүрә череп үләчәк...

Ислам дөньясы алдында татар халкын хурлыкка калдырмагыз!

Фәүзия БӘЙРӘМОВА,
язучы, тарих
фәннәре кандидаты.

Имам һәм мөдәррис

Халкыбызның рухи мирасы барланып бетмәгән. Архивларда, китапханәләрдә кул тимичә яткан борынгы кулъязмалардан, иске китап, газета һәм журналлардан табып кайтарасы бихисап галимнәребез, руханиларыбыз, зыялы шәхесләребез бар. Болар – үзләре яшәгән чор тарихының мөһим сыйфатларын җыйнап, буыннан-буынга тапшыруга сәләтле булган остазлар, акыл ияләре. Аларның эшчәнлеген, иҗатын өйрәнү һәм таныту өчен махсус хәзерлеге һәм, иң әһәмиятлесе, бу эш белән шөгыльләнергә теләге булган яшь буын галимнәргә бүген ихтыяҗ гаять зур.

Бу язмада шундый өйрәнелми килә торган руханиларыбызның берсенә – имам һәм мөдәррис Сәрвәретдин бине Мифтахетдин шәхесенә тукталасы килә. Быел аның тууына 150 ел тула, әмма, ни кызганыч, XX гасыр башында берничә китап язып бастырган, даими рәвештә Риза Фәхретдин чыгарган «Шура» журналында язышкан бу автор турында татар җәмәгатьчелегенең мәгълүматы юк, хезмәтләре дә әйләнешкә кереп китә алмый. Бабасының мирасын таныту өчен җан аткан оныгы – математика буенча дөньякүләм танылган галим, физика-математика фәннәре докторы, Мәскәү дәүләт университеты профессоры Иҗат Хак улы Сабитов фикеренчә, Сәрвәретдин бине Мифтахетдин – үз заманының күренекле укымышлысы дип аталуга лаек. Шәехзадә Бабич аның турында «Китаб-ен-нас фи хакк-әл-хавас»(«Күренекле шәхесләр турында китап») исемле әсәрендә хәтта аерым эпиграмма да язып калдырган:

Сәрвәретдин Мифтахетдин – һәм мөдәррис, һәм имам.

Ул тугандук «ислам, ислам, ислам, ислам...» дип туган!

Оныгының тырышлыгы белән Сәрвәретдин хәзрәтнең исеме «Татар энциклопедиясе»нә кертелде һәм русча басылган V томда (Казан, 2011) аның турында түбәндәге мәгълүмат урын алды.

Дин эшлеклесе һәм мәгърифәтче Сабитов Сәрвәретдин Мифтахетдин улы 1862 елда Казан губернасы Чистай өязендә (кайбер чыганаклар буенча Самара губернасы Бөгелмә өязендә) туган. Троицк мәдрәсәсендә белем алган, 1890-1913 елларда Оренбург өязенең Бушман-Суун-Каракыпчак волостеның Теләүмбәт авылында имам-хатыйб һәм мөдәррис булып торган, 1913 елдан Оренбург өязенең Югары Биккүз авылында яшәгән. Ысулы җәдит мәктәпләрен оештыру белән шөгыльләнгән. Ислам дине белеме, педагогика буенча хезмәтләре бар: Вәзаифе инсан – Казан. 1898. Әдәбе тәзәввүҗ – Оренбург. 1908. Ислам. Тәрәккый. Ислах. – Казан. 1913.

«Татар энциклопедиясе»нә кадәр үк, тарих фәннәре кандидаты Денис Денисов Уфа, Оренбург архивларыннан Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең тормыш юлы белән бәйле документлар табып, «Уралда ислам» энциклопедиясендә (2009) беренче булып, аның хакында аерым бер мәкалә бастырган иде. Анда Сәрвәретдин хәзрәтнең Төркиядә белем алуы, 1907 елда Бушман-Суун-Каракыпчак волостеның мөселман җәмгыятен төзүдә башлап йөрүе һәм аның рәисе булуы, актив рәвештә җәдитчелек идеяләрен, аеруча мәдрәсәләрдә рус телен һәм дөньяви фәннәр укытуны яклавы, шуның аркасында кадимчеләрнең яла ягуларына дучар булуы, бай китапханә туплавы һ.б. мәгълүматлар хәбәр ителә. Вафат булу тарихы 1916 елдан соң дип әйтелә. Д.Денисов хәзерләгән белешмә бүген Сабитов Сәрвәретдин Мифтахетдин улының тәрҗемәи хәле буенча иң тулы чыганак булып тора, ләкин, кызганыч ки, монда да сораулар күп, бу өлкәдә әле эзләнәсе бар.

Нигездә,Сәрвәретдин хәзрәт китапларының саны җиде-сигез булып, аларны Казан һәм Мәскәү китапханәләреннән табу кыен түгел. Кыен булганы – авторның телен һәм әйтергә теләгән фикерен ачык аңлау мәсьәләсе, чөнки Сәрвәретдин бине Мифтахетдин XX гасыр башы сөйләм теленнән аермалы буларак, шактый күп гарәп һәм фарсы сүзләрен кулланып, гаять катлаулы дини-фәлсәфи темаларга язган әсәрләрен өстән генә карап чыкканда да, аның ислам фәлсәфәсе, дин социологиясе буенча тирән фикер йөртүен күреп була. Ләкин бүген дә бу фәннәр буенча татарча атамалар (терминнар) эшләнмәвен һәм саф татар телендә гыйльми хезмәтләр язылмавын искә алсак, нигә һаман Сәрвәретдин хәзрәт әсәрләренә галимнәрнең кулы тимәвен фаразларга була: теле авыр, темасы катлаулы, атамалар аңлашылмый. Шул ук вакытта Сәрвәретдин хәзрәт кулланган фәнни тел, нигездә, аның белән бер чорда яшәгән дин галимнәре Муса Биги, Зыя Кәмалиләрнең теленнән әллә ни авыр түгел, дип әйтергә мөмкин.

«Шура» журналында басылган мәкаләләре буенча гына фикер йөртсәк тә, Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең берничә зур күләмле язмасында Аллаһның берлегенә нигезләнгән тәүхид темасын күпьяклап эшләвен күрәбез, шулай ук галим үз заманы фәннәренең ислам дине белән мөнәсәбәтен, диндә тәкълид (иярүчәнлекнең) урынын, исламдагы әхлак мәсьәләләрен яктырта, европалылар күзлегеннән чыгып караганда мөселманнарның тормышы ничек күренүен анализлый. Мәкаләләрнең күпчелегендә тәнкыйди караш өстенлек итә: язучы ислам әһелләре арасындагы торгынлыкны, мөселман дөньясының Европадан артта калу сәбәпләрен эзләгәндә христиан миссионерларын гына сүгеп калмый, мөселманнарның үзләрендә дә кимчелекләр күп булуын әйтә. Мәсәлән, «Шура» журналының 1911 елның 13 нче санында чыккан «Исламның хәле хазирәсе вә бүгенге мөселманнар» мәкаләсеннән бер өзек китереп, авторның тел-өслүб үзенчәлекләренә һәм фикер сөрешенә игътибар ирик:

«Әгәр дә хәзрәти пәйгамбәр шимдики (хәзерге) заманда кабереннән кайтып, шимдики өммәтләренә нәзар кыйлса (караса) иде. «Бунлар бәнем өммәтем дәгел (түгел)», – дия белгел (дия алыр), анлардан фырар идәр (качар) иде. Чөнки хәзерге өммәтләренең гамәлләре, хәрәкәтләре исламиятнең асыл мәүзугы (темасы) вә кавагыйде мөкатдәсенә (изге кагыйдәләренә) бигрәк хилаф (хата) улынмактадыр», – дип сүз башлый автор. Үз заманы гыйлемнәренең хыялдан гына гыйбарәт булуын, мөселманнарның тәрбиясенә һәм үсешенә файда китермәвен әйтеп, автор, бу гыйлемнәрнең чын дини тәгълиматтан һәм Коръән хакыйкатеннән тулысынча ерак калуын тәнкыйть итә. Үз чоры галимнәренең «нәфак (шом һәм дошманлык тудыру), рия (икейөзлелек) вә мөдаһнә (ялагайлык), хөсед (көнчелек) вә гайбәт, бөһтан (яла ягу) вә ифтира (нахак сөйләү) кеби зәмаим (начарлык) илә мөтассав (тулган) иделдекләре күрелер», – ди (389 б.)

Үз дәвере суфилары һәм тарикатьләр (суфи оешмалар) турында Сәрвәретдин хәзрәт болай ди: «Хәлбуки хәзерге голамәмез илә шәйхләремез вә суфиларымыз бу көндә бөтен мөселманнарның мөкатдәсләре (изгеләре) вә юлбашчылары булып, бөтен галәме ислам аларның тәрбияләрендәдер. Боларның күбесе асыл исламиягә вә рәсуллаһның сөннәт рәшидәсенә муафикъ дәгел (туры килмәгән) кагыйдәтәр илә мөселманнарны тәрбия кыладыр. Хәзерге тарикъләр вә кагыйдәләрне гакыл вә хикмәт үзрә татбик идеп (чагыштырып, тикшереп) карасак, бу икенең арасында һич тә мөтабакат (охшашлык, туры килү) күренмәс. Аларның күбесе бидгать (исламга соңыннан кертелгән яңалык) вә дузмәләрдән (уйдырма) гыйбарәт, әсас хакыйкатьдәп хариҗдыр (читтә, тышта)», – ди. Европалыларның мөселманнарга кимсетеп каравына мөселманнар үзләре дә гаепле, чөнки алар хокукларын белми һәм якламый, ди. Әлеге фикер – «Шура»да 1913-1914 елларда басылган «Ислам вә мөселманнар» мәкаләсендә дә дәвам иттерелә.

«Европалылар вә шимдики мөселманнар» («Шура», /9// М/4. 427-4.96) исемле

Сәрвәретдин Сабитов

мәкаләсендә исә автор мөселманнарга һәм исламга дошманлык яки тәнкыйть күзе белән караучы европалыларны өч группага бүлеп күрсәтә һәм һәрберсенә төпле бәяләмә бирә. Беренче төркемгә ул миссионерларны кертә: алар, христианнар белән мөселманнар арасындагы сәяси каршылык һәм көрәшләр тарихын гел истә тотып, үзара дошманлык хисен арттырып тору яклы, ди. Автор Шам (Сүрия), Мисыр, Әндалусиядә булган ислам-христиан бәрелешләрен, хәлифәлекнең Госманлы дәүләтенә күчкәннән соң булган дини юнәлешле сугышларны анализлап, христиан миссионерларның «төп максаты бу дөньядан әһле исламны юк итү» икәнлегенә басым ясый. Миссионерларны, кайчан да булса ислам дине өстен килер дә, мөселманнар бар дөньяга хуҗа булыр, дигән курку тойгысы биләгән. Шуңа күрә алар бар көчләренә мөселманнарны каралту, аларга яла ягу белән шөгыльләнә, ислам динен золым итеп күрсәтергә тырыша, ди.

Икенче төркемгә «исламның хөкемнәрен аңламаган Ренан һәм башка Европа философлары» керә. Автор фикеренчә, бу акыл ияләренә барлык диннәргә, хәтта христианлык, яһүди һәм ислам тәрбия ысулларына да түбәнсетеп карау хас. Болар исламга миссионерлардан да көчлерәк һөҗүм итә, аларның карашы буенча, исламның мәдәният белән бер бәйләнеше дә юк, бу дингә кыргый бер тәгълимат дип карый, ди. Сәрвәретдин хәзрәт өченче төркемгә материалистлар һәм рационалистларны аера. Болар бар нәрсәне акыл һәм мантыйк күзеннән генә тикшереп, фәнгә мөнәсәбәттә бәяли, шуңа күрә ислам динендәге кайбер догмаларны кире кага. Мәсәлән, Коръәндә әйтелгән җиһанның алты көндә яратылуы. Адәм галәйһиссәламнең җирдәге бар кешеләрнең атасы булуы, хатын-кызларның аның сөягеннән яратылуы, туфанда Нух пәйгамбәрнең терәклекне коткарып калуы һ.б вакыйгалар физиология фәненә бөтенләй туры килми дип ассызыклыйлар, ди.

Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең «Шура» журналының 1908-1909 елгы саннарында урын алган зур күләмле «Тәүхид, хәят, ислам» мәкаләсе, 1898 елда басылган «Нәүгы бәшар» («Кешелекнең яратылышы») китабы кебек, дөнья яратылышы, эволюциясе һәм киләчәге турында фәлсәфи уйлануларга нигезләнгән. Китабына язган кереш сүздә ул, хәзерге телгә күчереп әйткәндә, болай ди: «Барлык адәм балалары өстенә кешелеккә хас булган күркәм сыйфатларны тулы рәвештә саклап калу һәм бөтен тиешле вазифаларны Аллаһның хикмәте вә намус кушканча үтәү бурычы йөкләнгән. Һәрбер кешегә үзен һәм Хакыйкатьне танып белү, Аллаһының хикмәте белән бәйле намус кануны кушканча хәрәкәт итүе дә тиеш булганга, адәм балаларының күркәм сыйфатларын тасвирлауга багышланган кечкенә генә бер хезмәт яздым. Ватанпәрвәрлегемнең нәтиҗәсе булган бу хезмәтнең язылуы ватандашларым өчен бер үрнәк һәм аңлатма булуын гына телим».

Ун ел соңрак басылган мәкаләсендә дә автор әлеге максатны күздә тотып, адәм баласының дөньяга яратылган вакытыннан алып ия булган үзенчәлекләрен аңлата һәм аларның ни рәвешле үстерелә алуы турында сөйли. Аның фикеренчә, адәм баласының тормышы бер-берсе белән бәйле булган ике нәрсәгә нигезләнә: берсе – кешенең туганда ук үзенә бирелгән мөмкинлекләрен, сәләтен, теләкләрен күрә һәм бәяли белүе, икенчесе – гыйлем һәм мәгърифәт. Кешеләрнең күркәм сыйфатларын (Фазиләтләрен) өч төргә бүлә: 1. Нәфес сыйфатлары (фазаиле нәфсия). 2.Тән (гәүдә) сыйфатлары (фазаиле бәдәния) 3. Иҗтимагый сыйфатлар (фазаиле иҗтимагыя). Бу сыйфатларның һәрбере язмада аерым-аерым аңлатыла һәм тәрбия нәтиҗәсендә үстерелә алу мөмкинлеге әйтелә. Алар арасында иң әһәмиятлесе итеп Сәрвәретдин хәзрәт беренче төрне күрсәтә, чөнки нәфес фазиләтләренең нигезен тәүхид һәм мәгърифәт тәшкил итә, тәһарәт, гыйбадәт, гадәләт, гыйффәт кебек әхлак сыйфатлар тулыландыра, ди. Дин, яратылыш, кешенең яратылыштан ия булган үзенчәлекләре бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тора, гыйлем һәм мәгариф ярдәмендә тәрбия иткәндә кешенең акыл (акли) һәм дини гыйлемнәрдә зур мөмкинлекләргә ирешә алуы әйтелә.

Күргәнебезчә, мәкалә, дин социологиясе күзлегеннән чыгып, инсан тәрбиясе, рациональ һәм дини гыйлемнәр ярдәме белән кешенең җитлегү, үз-үзен үстерү мөмкинлеге һ.б. хакында укучыларга юл күрсәтүне максат итеп куя, дин аша гуманизм идеяләрен күтәрә. Галимнең аңлату ысулы, гарәпчә-фарсыча гыйбарәләрне һәм атамаларны еш куллануга карамастан, тәфсилле һәм эзлекле дип әйтергә кирәк.

Хәзрәтнең эшчәнлеген хронологик яктан күзәткәндә, үзе күтәргән катлаулы темаларга аның кабат-кабат кайтып эшләвен күрәбез. Мәсәлән, 1898 елда Казанда нәшер ителгән «Вәзаифе инсан» («Кешенең вазифалары») китабындагы фикерләр соңрак «Шура»да басылган тирән эчтәлекле мәкаләләрендә дәвам иттерелә. Өйләнешү һәм гаилә этикасы темасына багышланган «Әдәбе тәзәввүҗ» («Өйләнешү әдәбе») (1908) һәм «Балалар тәрбиясе» (Эстәрлетамак, 1911) китаплары шәригать нигезенә корылган тәгълим-тәрбия, ягъни педагогика фәне буенча тәүге татарча дәреслекләр рәтендә санала ала. Изге китапның һәм гарәп теленең мөһим хосуслары турында язылган «Коръән газыйм» (Оренбург, 1903) һәм «Коръән шәриф» (Оренбург, 1911) исемле хезмәтләрендәге фикерләр «Шура» журналында 1912-1914 елларда басылган күләмле «Тәгъдиде әхвале инсан вә Коръән», «Хакыйкый ислам вә тәрбия» мәкаләләрендә дә дәвам ителә. Сәрвәретдин бине Мифтахетдин Оренбургта Р.Фәхретдин җитәкләгән «Шура» журналы белән актив эшчәнлеген бу басма рәсми рәвештә ябылганга кадәр алып бара, иң соңгы язмасы «Диннәр хакында нәзарият» 1917 елның 3-10 саннарында урын алган. Гомумән, «Шура» журналының библиографиясенә караганда, Сәрвәретдин бине Мифтахетдин дини темаларга иң күп мәкалә язучы авторлардан хисаплана ала. XX гасыр башында чыккан башка журналларда да Сәрвәретдин хәзрәтнең язмалары булуы бик мөмкин.

Китаплары арасында махсус тукталып тикшерү-өйрәнүне сорый торган «Ислам. Тәрәккый. Ислах» («Ислам. Прогресс. Реформа») 1913 елда Казанда басылган һәм безгә мәгълүм соңгы китабы санала. Бу әсәрендә авторның бер бүлектә шул чорда хәлифәлек мәркәзе булган Төркиядә алып барылган мәгариф сәясәтенең дөрес булмавы хакында әйтелгән тәнкыйть фикерләре, Госманлы империясенең тарихын һәм бүгенгесен яхшы белүе, гомумән, кулланган теленең дә госманлычага нык якын торуы Сәрвәретдин хәзрәтнең ниндидер бер сәбәп белән (мәсәлән, белем алу яки хаҗ юлында тукталу) чынлап та күпмедер вакыт Төркиядә яшәвенә ишарәли.

Югарыда әйтелгәнчә, имам һәм мөдәррис Сәрвәретдин бине Мифтахетдин әсәрләрен аңлау һәм анализлау өчен зур көч сарыф итәргә, махсус рәвештә җентекләп шөгыльләнергә кирәк. Тик шунысы шиксез, мәгърифәтче һәм дин галиме буларак, ул тормышын үз халкына хезмәт итүгә багышлаган, әсәрләре белән җәмгыять әхлагын тазартырга милләтенең дөньяга карашын киңәйтергә, рухи байлыгын, тән һәм җан сихәтлеген арттырырга омтылган. Әлбәттә, Мифтахетдин улы Сәрвәретдин Сабитов кебек зыялы милләт хәдимнәребез татар рухи мирасы тарихында кирәгенчә бәяләнергә,онытылмаска, хөрмәт белән искә алынырга лаек.

Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы,
профессор.
Мәскәү.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

5 февраль (шимбә). ***Рәҗәб аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,9.20 сәгатьтә калка, 21.37 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.56 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу арада әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь.

Сихәтле кабак төше

Простатитны кисәтү өчен, болай дәвалану яхшы. 250 г кабак төшен тарттырып, 200 г чәчәк яки карабодай балы кушалар, әйбәтләп болгатып, суыткычка куеп торалар. Масса куергач, әстерхан чикләвеге зурлыгында шарчыклар әвәлиләр (аларны суыткычта саклыйлар). Иртәнге ашка 30 минут кала берәр данә ашыйлар. Әзерләнгән шарчыклар беткәнче дәвалананалар, бер елдан соң кабатлыйлар. Кайберәүләр бу рецептны җиңеләйтә: кабак төшен порошок итеп төяләр дә, ашарга 30 минут кала 1 аш кашыгын шулкадәр үк бал белән кабалар, артыннан 1 стакан су эчәләр. Дәва курсы – 2,5-3 ай, 1 елдан соң кабатлау мәслихәт.

6 февраль (якшәмбе). ***Рәҗәб аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,9.29 сәгатьтә калка,23.17 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 9.01 сәгать.***

Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Ютәлдән – шалфей

Ютәлләгәндә, 1 аш кашыгы шалфейны 1 стакан суда кайнатып чыгаралар, йокларга ятканда кайнар килеш эчәләр. Яисә 1 стакан уылган кызыл чөгендергә 1 аш кашыгы алма серкәсе кушып болгаталар да, бераз төнәткәч, согын сыгып алалар, аннары шуның белән тамакны чайкыйлар.

7 февраль (дүшәмбе). ***Рәҗәб аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,9.38 сәгатьтә калка, 0.35 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 9.05 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Урт ялкынсынса

Еш кына урт ялкынсына, гингивит башлана. Организм хәлсез булып, С витаминына кытлык кичерсә, хәл тагын да авырая: уртта җәрәхәтләр барлыкка килә, алар шешә һәм каный. Бу очракта кәбестә ярдәмгә килә. Яңа сыгылган кәбестә согын шулкадәр үк кайнаган суга кушалар да, авызны чайкыйлар. Петрушка төнәтмәсе дә ялкынсынуны баса, ул шулай ук авыздагы сасы исне дә бетерә.

8 февраль (сишәмбе). ***Рәҗәб аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,9.49 сәгатьтә калка, 1.52 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.09 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

9 февраль (чәршәмбе). ***Рәҗәб аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,10.02 сәгатьтә калка, 3.09 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.13 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

10 февраль (пәнҗешәмбе). ***Рәҗәб аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,10.21 сәгатьтә калка, 4.21 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.17 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Тырнакны май ныгыта

Организмга кремний, тимер, кальций җитмәгәндә, тырнаклар катламлана, сынучанга әйләнә. Шунлыктан кремнийга (кузаклы фасоль, салат, банан, петрушка, карлыган), тимергә (йомырка сарысы, сыер ите, бавыр, чөгендер, борчак, ногыт борчагы, кипкән җиләк-җимеш), кальцийга (сыр, эремчек, чикләвек) бай ризык ашарга киңәш ителә. 1 чәй кашыгы зәйтүн маена бернечә тамчы лимон согы тамызалар да, тырнакка сөртеп, киҗе-мамык перчатка киеп, йокларга яталар, 1 ай буе шулай дәваланалар. 1 литр җылы суда 1 аш кашыгы диңгез тозын эретеп, кулларны шуңа тыгып, 5-7 минут утыру да файдалы. Атнасына 3 тапкыр дәваланырга кирәк, 10 тапкырдан соң уңай нәтиҗә күренәчәк. Чын балавызны бераз эретеп, кич тырнакларга сылап киптерәләр дә, иртәнгә кадәр калдыралар, бу да тырнакларны ныгыта.

11 февраль (җомга). ***Рәҗәб аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,10.48 сәгатьтә калка, 5.46 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.21 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Бәрәңге печеньесы

1 кг бәрәңге, 2 йомырка, 2 аш кашыгы сары май, тоз, борыч кирәк. Пешкән бәрәңгене кайнар килеш угычтан уалар, тоз, борыч, йомырка сарысы, сары май кушып болгаталар, аннары күпертелгән йомырка агын кушалар. Массаны кондитер капчыгына яки полиэтилен пакетка салып, майланган табага түгәрәк яки озынча формада сытып чыгаралар, газ мичендә пешерәләр.

Кызлар җырлый

Кулыма әле генә табадан төшкән “Илһамлы кызлар җыры” дигән шигырьләр җыентыгын алдым. Китап кызларга хас зәвыклылык белән эшләнгән. Тамырлары белән җирнең үзәгенә береккән мәһабәт агач янында кулларына чәчәк гөлләмәсе тоткан зәңгәр күлмәкле хатын-кыз рәсеменең китап тышлыгында урын алуы ук мәгънәле. Шигърият – тормышның үзе кебек үк борынгы. Агач үзенә яшәү көчен җирнең шифалы дым чыганагыннан алса, кешелек үзенең яңарып торуы белән хатын-кызга бурычлы. Шул ук вакытта күңелләре белән шагыйрәнә булмаган аналар юктыр да ул. Тик аерма шунда – аларның күпчелеге үзләренең шагыйрь булуын белми. Бик сирәкләре генә әнә шул күңел байлыгын башкаларга да ирештерү сәләтенә ия. Шөкер, бездә талантлары белән сөендерүчеләре елдан-ел арта тора. Күзәтүемчә, хатын-кыз шагыйрьләр тел хасиятләренә аеруча талымлы.

Шигырьләрне иҗат итүчеләргә генә түгел, аларны кабул итүчеләргә дә телне үзәгенә үтеп белергә кирәк. Шуннан башка автор җиткерергә теләгән гамь, синең аң төпкеленә үтеп кермичә, шигырь юлары өстеннән шуып кына узып китәргә мөмкин. Башка телдә язылганнары бигрәк тә шулай. Бер телдән икенчесенә тәрҗемә шушы ихтыяҗ белән барлыкка килгәндә туа. Әмма тәрҗемәгә алынучыга исә ике телне дә камил белү өстенә үзе дә шагыйрьлек һәвәсләгеннән мәхрүм булмаска тиеш. Чөнки һәр тел –аның хуҗасы булган халыкның тарихы да, күңел дөньясы, яшәү рәвеше, фикерләү рәвеше дә. Шул нечкәлекләрне башка бер телдә яңгырату шуларны яхшы белүне һәм, әлбәттә, осталык таләп итә.

Сүзебез тәрҗемә мәсьәләләренә килеп чыкты. Бу очракта китап исеменә кергән “илһамлы кызлар” – рус телендә иҗат итүче шагыйрәләр иҗатына кагылырбыз. Бер түбә астында Вера Арямнова, Елена Бурундуковская, Лидия Григорьева, Саша Кашина, Ольга Левадная, Вера Хәмидуллина кебек үз ана телендә иҗат итүчеләрнең, милләттәшләребез – рус телендә каләм тибрәтүче Наилә Ахунова, Альбина Әпсәләмова, Лилия Газизова, Роза (Баубекова) Кожевникованың әсәрләре тупланган. Аларны, төрле милләтләрдән булуларына карамастан, рус телендә язу берләштерә.

Рус телле шагыйрәләрне татар телендә сөйләштерүче кем соң? Индус Сирматов икән. Монысы аеруча гаҗәпләндерде. Индус Фатих улы барыбыз өчен дә яхшы таныш. Чөнки ул алтмышынчы-сиксәненче елларда Казан телевидение студиясендәге әдәбият-сәнгать бүлегенең төп көчләреннән берсе булды. Индус әфәнде бер үк вакытта проза өлкәсендә иҗат итте. Аның образлы каләменә А. Гыйләҗев һәм М. Хәбибуллин кебек халык язучылары да матур бәя бирде. Белүемчә, үзе шигъри әсәрләр язмады кебек. Ә монда тулы бер шигъри китап! Шуңа әлеге җыентык мине аеруча кызыксындырды. Баксаң, ул шигъри тәрҗемә белән утыз-кырык еллар буе шөгыльләнә икән. Теләсә кайсыларын түгел, нәкъ менә күңеленә ошаганнарын гына. Ул кайберләрен матбугатта бастырып та килгән. Менә хәзер алар бер китаплык җыелган икән. Ниһаять, “Татнефть” хәйрия фондының “Рухият” нәшрияты аның дөньяга чыгуын тәэмин иткән. Әлеге фонд эшлекләләре Флера Шәйхетдинова, Рамил Миңнуллиннарга аерым рәхмәт әйтү тиеш.

Инде, хуш, китапта урын алган әсәрләр турындагы тәэсирләргә күчик. Биредә 12 авторның шигырьләре тупланган. Шәлкемнәр алдыннан шагыйрәләр турында белешмәлек бирелгән. Авторлар шәхес һәм шигъри һәвәслелек ягыннан бер-береннән нык аерылып торган кебек, язганнарының да төрле-төрле булуы табигый. Шигъри гөлләмәләр тезмәсен ачучы Вера Арямнова сүзне күңел халәтен көйләү өчен язуын бәян итүдән башлый.

Шигырьләрем мине коткаралар
Кайгы, хәсрәт, бәла-казадан.
Җәрәхәтле күңел дәвалана,
Җанга шифа табам аларда.

Лилия Газизова исә шигырь язуының сәбәбен башкачарак күрсәтә:

Бер яшь егет күрсен мине,
Күзен алмый күзәтсен ул.
Ишеткәндәй тәүге кабат,
Шигыремне тыңласын ул.

Елена Бурундуковская шигырь язгандагы ярсулы халәтендә күзаллана.

Тормышымның дәреслеген язам,
Язамын да ертам битләрен.
Кабатлаулар монда кирәк түгел,
Өлгералмый калсам, нишләрмен?

Икенче бер шигырендә бәян ителгәнчә, ул язмый. Язмагач, ертасы да юк. Шунысы кызык, аны шул халәте канәгатьләндерә.

Әле анда язылмаган бер сүз,
Кичә дә ул шулай чиста иде.
Әйдә, шулай чиста көе торсын,
Тормышымның дәреслеге булсын.

Иҗади халәтне шулай каршылыклы итеп күрсәтү, ихтимал, каләм тибрәтүченең күңелендәге давылланып алуларның ара-тирә кискенлеге, көтелмәгәнлеге, шулай ук кинәт тынып калулары белән аңлатыладыр. Хәер, хәзерге шигъриятгә башваткыч булып әверелердәй тезмәләрнең еш очравына күнегеп барабыз инде. Әмма шунысы хак, шулай да иҗат максатың ачык булуы отышлырак. Е.Бурундуковская эзләнә, темаларның төрлелеге шуны раслый. Көзнең соңгы мизгелләрен сурәтләгәндә лирик герой белән агачта эленеп калган ялгыз яфрак арасында параллель уздыруы гына да уңышлы табыш дип санала ала.

Ә агачта калган соңгы яфрак,
Сары яфрак, ялгыз, бердәнбер.
Ул көрәшкә чыккан җилләргә дә,
Тормышта да каршы бергә-бер.

Ләкин хатын-кыз җилләргә каршы тору мөмкинлегенең булуын үзе дә чамалап бетерми. Ул, ихтыяҗ булганда, ихтыярын җиңүгә тупларга сәләтле.

Хатын-кыз барысын җиңәргә,
Түзәргә яратылган.
Татлы газаплану хисе
Бүләк ителгән аңарга
Тәңресе тарафыннан.

Шагыйрә газаплануның татлы да була алу хасиятен хатын-кыз түземлелегенең бер сыйфаты буларак билгели, шуның белән аның ихтыяр ныклыгының асыл нигезе ачыклана.

Лидия Григорьева да җилнең, төрле төсмерләргә кереп, үзен һаман эзәрлекләвеннән зарлана.

Болай тупас булырга соң –
Кара син аны!
Димәк, шулай кирәк инде –
Түз генә, җаным!

Ләкин аның җаны үзенең шәхси тоемнары белән генә чикләнмәгән, матурлыкны күрү һәм аңардан ләззәтләнүдән мәхрүм булып тупасланмаган. Аңарда татар егетенең гармунда өздереп уйнавын тәэсирлелек ягыннан Бах көйләре белән тиңләштерерлек киң күңеллелек бар.

Мин музыка белән уралган,
Мин музыка белән төренгән.
Бөтен кальбем, җаным, хисләрем
Сихер дәрьясына күмелгән.

Атаклы шагыйребез Равил Бохараев хатынының бу шигыре җыентыкта татар рухын чагылдырган шактый сирәк әсәрләрнең иң уңышлыларыннан берседер. Аның янына Альбина Әпсәләмованың “Әбиемә” шигырен куярга мөмкин. Ул “Ак чәчәкләр” романы авторы Г. Әпсәләмовның хатыны Маһинур ханымга багышланган. Заманында бик көяз, сүзчән бу апаның аш-су остасы дигән даны таралган иде. Бисмиллалы ризык әзерләүне җиренә җиткереп эшләргә бер дә иренмәгән ул.

Юлга чыксам, “Бисмилла” дидең,
Юлың уң булсын, саграк йөр, дидең.
Их, әбекәем, кире кайтсаңчы,
Сине сагына карт алмагач та.

Элгәрләрне, эти-әниләрне сагыну мәүзугы Наилә Ахуновада аеруча зәвык белән күтәрелә. Шагыйрәнең:

Калебемә якын минем
Аһәңе туган телнең, –

дип әйтүе әлеге тасвирлар чолганышында аеруча матур яңгырый. Арча ягы турында әйтелгән менә бу юллардагы бәя дә, Наиләнеке генә булмыйча, тулаем халкыбызныкы кебек кабул ителә:

Монда бабамнар минем
Дөнья көткән, көн иткән.
Җиргә башларын салып,
Мәңге йокыга киткән.

Н.Ахунованың шулай фикерләве табигый. Ул милли әдәбият мохитендә тәрбияләнгән. Ә менә Урал төбәкләренең берсендә туып-үскән, әмма язмышы Татарстан белән үрелгән Вера Хәмидуллинаның мондый юнәлештәге хис-кичерешләре гәүдәләнгән әсәрләренә тап булу да куандыра. Аның җыентыкта бирелгән шигырьләр гөлләмәсенең “Халыклар дуслыгы – җиңелмәс көч ул” дип исемләнүе үк игътибарны җәлеп итә. Биредәге шигъри юлларда Татарстан, Казан, халыкларның телләренә мөнәсәбәтле әйтелгән фикерләрдән күңел хушлана.

Мең елдан килгән гадәтен саклап,
Купшы бизәнеп иртә язларың,
Киң күңел белән колачын җәеп
Кунак каршылый гүзәл Казаным.

В.Хәмидуллина телләрне тау чишмәсенә тиңләштерә. Алар,күңелләрне сугаруларын, рухларыбызга көч өстәвен дәвам иттерсә, яшәеш мәңге шиңмәс, дип киләчәккә өмет белән карый. Бу чишмә-телләрнең алдагы ерак дәверләргә тыгыз үрелгән хәлдә, бер-берләрен баетып барачагына ышана.

Кабул ит, Аллам, теләкләремне,
Мәңге сакла чишмәләремне! – ди.

Шулай гына була күрсен!

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.

Вафат СССРның йөз еллыгы

2022 ел азагында СССР атлы империя төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итәрләр иде дә, әмма черек аяклы колосстай җимерелеп төшүенә дә утыз ел тулды инде. Халыкның өлкән буыны аны бүген дә бик сагына, ә замана яшьләре, аеруча мәктәп балалары андый супердержава булганын да белми...



СССР империясенең нигезе булачак тәүге Россия Республикасы 1917 елның 1 сентябрендә игълан ителә. Аны РСФСР белән бутамагыз. Ул октябрь инкыйлабыннан соң Совет Россиясе дип атала башлый, ә 1918 елның 10 июлендә кабул ителгән Конституциядә РСФСР дип языла.

Совет Россиясен генераллар Лавр Корнилов, Николай Юденич, Антон Деникин, Пётр Врангель, адмирал Александр Колчакның гаскәрләре, атаман Александр Антонов һәм батько Нестор Махноның партизан армияләре, Антанта интервентлары чолгап ала. Ләкин В.Ульянов (Ленин) рәислегендәге Халык Комиссарлары Советы, тәүге хәрби нарком Лев Троцкий җитәкләгән Эшче-крестьян Кызыл Армиясе (РККА) зур корбаннар биреп, дошманнарны җиңеп чыга. Гражданнар сугышында ата – улга, улы бертуганнарына каршы корал күтәрә, нәтиҗәдә ун миллион россиянлы кеше һәлак була. Биш миллионга якын сәләтле кеше, Россияне ташлап, мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр ителә.

1918 елның 3 мартындагы Брест солыхы нигезендә күп территориясен югалткан Совет Россиясе, җирләренең күбесен (Көнбатыш Украина, Бессарабия (Молдавия), Көнбатыш Белоруссия, Литва, Латвия, Эстония, Польшаның кечкенә бер өлешен), 1939 елның 23 августында кул куйган Молотов-Риббентроп пакты буенча Сталин кире кайтарып алуга ирешә.Әмма Финляндия белән Польша кире кайтарылмый, чөнки Финляндия Республикасының дәүләт бәйсезлеген Ленин рәислегендәге Халык Комиссарлары Советы 1917 елның 18 (31) декабрендә үк таный, ә поляклар 1920 елның август аенда Михаил Тухачевский гаскәрләренең һөҗүмен Варшава янында туктата.

1940 елгы кышкы кампаниядә сугышып, финнардан да шактый җир тартып алына, мәсәлән, Ленинград шәһәре һәм өлкәсе, Карелия ярымутравы территориясе киңәйтелә.

Туган илебезне какшату Сталинның Кунцеводагы яки "Ближняя" дачасында коры шәраб, "Боржоми" суын эчеп, кәефләнгән чакта генераль секретарь бие дигәч, өстенә милли украин күлмәге киеп, матур итеп биегән хохол Хрущёвтан, аның "җепшеклеге"ннән башлана. Югыйсә, Хрущев та Сталинның "турылыклы" шәкерте һәм каешланып беткән коммунист булып санала. Шул Хрущёв партиянең Мәскәү шәһәр комитетын җитәкли башлагач ул 100 мең тирәсе "троцкийчы-зиновьевчылар"ны репрессияләтеп бетерә. Ләкин Кремльдә хакимият өчен көрәш башлангач, астыртын, мәкерле эш йөртүче "такыр баш" барыбер җиңеп чыга...

Михаил Горбачёвның "үзгәртеп коруы" аркасында көчле, куәтле Советлар Союзы һәлакәткә очрады һәм ахыр чиктә үзүзен үтерде.

Гомумән, 1922 елда СССР төзелү тарихын өйрәнгәндә, бер мөһим мәсьәләгә игътибар итми булмый. Совнарком рәисе В.Ленин Гражданнар сугышында Совет власте дошманнарын җиңеп чыгар өчен, илебез халыкларына автономияле һәм союздаш республикалар "бүләк итә", ягъни төзергә рөхсәт бирә. Мондый хәл, хәзерге телдә әйтсәк, "суверенитетлар парады" рәвешен ала. Мәсәлән: Ленин имзалаган Совнарком декретлары буенча РСФСР 1918 елның 18 ноябрендә Латвия, шул ук елның 22 декабрендә Литва Республикаларының бәйсезлеген таный. 1919 елның 5 февралендә Белоруссия ССРның бәйсезлеген тану турында рәисе Яков Свердлов имза куйган Бөтенроссия ЦИК Президиумының карары кабул ителә. 1920 елның 2 февралендә РСФСР белән Эстония Республикасы Тарту солыхына кул куя, нәтиҗәдә Эстониянең бәйсезлеге танылa. 1919 елда Кече Башкортстан Республикасы, ә 1920 елны Татарстан АССР да шул рәвешле оеша.

Милли эшләр буенча халык комиссары И.Сталин иң башта Россия халыкларына милли-территориаль автономия бирү яклы була, тик соңыннан Ленин принцибы белән ризалаша. Ләкин унбиш милләткә Союзга керә һәм чыга алу хокукын бирү киләчәктә СССРның таралуына китерә.

Латвия, Литва, Эстониянең парламент сессияләрендә кабул ителгән декларацияләр нигезендә СССР составына 1940 елның 21-22 июлендә кергән Балтыйк буе республикалары Мәскәүгә, фактта инде 1990 елдан буйсынмый башлады, Союздан аерылып, мөстәкыйльлек юлау юлына басты. Кан коюлы бәрелешләрдән соң Үзәк аларга 1991 елда азатлык бирергә мәҗбүр булды. Шул ук елның 19-21 август көннәрендә ГКЧП дәүләт түнтәрелеше ясарга маташты. Аннан соң 8 декабрьдә Беловежская пущада Россия, Украина һәм Белоруссия җитәкчеләре Ельцин, Кравчук, Шушкевич Советлар Союзына "ясин" чыгып, аңа балта чапты, ә 25 декабрьдә СССРның беренче һәм соңгы Президенты М.Горбачёв телевидение аша мөрәҗәгать итеп отставкага китте.

Элек дус күршебез, аркадашыбыз, куәтле хәрби союзник саналган Кытай Халык Республикасы менә СССР хатасын кабатларга теләми. Кытай унитар, бердәм дәүләт булып яши бирә. Аларда бер партияле генә сәяси система хөкем сөрә, аларда һаман Коммунистлар партиясе идарә итә.

Илһам ФӘТТАХОВ,
филология фәннәре
кандидаты.

МТ тамаша байлары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

4 февраль – «Тормышмы бу?» (Г.Исхакый).
5 февраль – 12.00 – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров). 18.00 – «Сәфәр» (А.Шакиров). 19.00 – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).
6 февраль – Шәрык клубында 14.00 – «Бичара кыз» (Г.Ильяси). 18.00 «Өйләнәм.tat»(И.Зәйниев).
8 февраль – Зур залда – «Килә ява, килә ява» (З.Хәким). Кече залда – «Томан» (Г.Сәгыйтова).
10 февраль – Зур залда – «Сөясеңме, сөймисеңме..» (Ф.Бүләков). Кече залда – «Исәнме, улым!» (Б.Абдураззоков).
11 февраль – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

30 гыйнвар – 26 февраль – Ф.Шаляпин исемендәге 40 нчы халыкара опера фестивале:
4 февраль – «Пиковая дама» (П.Чайковский).
6 февраль – «Травиата» (Дж.Верди).
8 февраль – «Аида» (Дж.Верди).
11 февраль – «Паяцы» (Р.Леонкавалло).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

5 февраль – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
6 февраль – «Кияүләр» (Х.Вахит).
8 февраль – «Туй алдыннан» (Х.Вахит).
9 февраль – «Утка очкан күбәләктәй» (Н.Гыйматдинова әсәре, Т.Хәләф инсценировкасы).
10 февраль – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
11 февраль – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (Й.Миңнуллина, М.Гафурова, А.Бикбулатов, Э.Дусаева).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

4 февраль – «Арыну» (А.Әхмәдиев, Т.Кулов).
6 февраль – «Корт» (Ф.Галиев).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

4 февраль – Зур залда – «Приключения Барона Мюнхгаузена» (Р.Распе). Кече залда – «Су анасы» (Г.Тукай, З.Хөснияр).
5 февраль – «Маугли» (Р.Киплинг). Кече залда – «Су анасы» (Г.Тукай, З.Хөснияр).
6 февраль – Фойеда – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). Зур залда – «Сны Диснея» (И.Зәйниев). Кече залда – «Котбетдин маҗаралары» (Н.Гернет).
9 февраль – «Сны Диснея» (И.Зәйниев).
10, 11 февраль – Зур залда – «Волшебник изумрудного города» (А.Волков). Кече сәхнәдә – «Misterioso con anima» (Е.Ибраһимов).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

4 февраль – Танеев исемендәге квартет концерты.
6 февраль – 11.00 – «Петербургская оперетта» театры башкаруында «Кар патшабикәсе» әкияте. 17.00 – «Труффальдино из Бергамо» мюзиклы.
9 февраль – Олег Митяевнең «Ковчег» дип исемләнгән концерт программасы.

Канәфер чәйнисеңме?

Бу дөньяда файдалы һәм зыянлы гына түгел, шактый сәер гадәтләр дә бар. Мәсәлән, канәфер бөресен чәйнәү. Мондый "сагыз" Һиндстанда берничә гасырдан бирле популяр ул үзе, хәзер исә Европада да әлеге тренд бик актив мактала. Нигә дисезме? Әгәр көн саен ике-өч канәфер кадагын чәйнәп йотсаң, организмда уңай үзгәрешләр башлана икән. Канәфер мае ашкайнатуны яхшырта, эч күбенүдән саклый. Иртән күңел болганса, 10 минут канәфер бөресен чәйнәү җитә, әмма йөкле вакытта аны кулланудан тыелу мәслихәт. Бавыр эшчәнлеген дә яхшырта. Көчле йогышсызландыру үзлегенә ия әлеге бөреләрне чәйнәү уртларны сәламәтләндерә, авыздан килгән тәмсез исне бетерә – стоматологиядә канәфер мае хәтта вакытлыча пломба составына да керә. Канәфер чәйнәп йоту иртән хәтта каһвәдән дә шәбрәк дәртләндерә, чөнки организмдагы матдәләр алмашын тизләтә, әмма бу киңәштән кан басымы нормада булганнар гына даими файдалана ала. Канда шикәр микъдары аз булган кешегә исә саклану мәслихәт: канәфер мае глюкоза эшләнүне киметә, шунлыктан гипогликемия тагын да көчәергә мөмкин, хәтта аңны да югалту ихтимал. Канәфергә аллергия очраклары да шактый.

("Лента.ру").

Йоклаткыч йога

АКШтагы Гарвард университеты галимнәре йокысызлыктан коткара торган махсус күнегү булуын раслаган. Бу – "4-7-8" дип йөртелә торган сулыш техникасы, ул бер минут эчендә йокыга китәргә булыша. Башта 4 секунд буена борын аша суларга, аннары 7 секунд суламый торырга, аннары 8 секунд авыз белән суларга кирәк икән. Йокы килгәнче, шулай кабатлау зарур. Галимнәр әйтүенчә, әлеге ысулны һинд йогалары медитация процессында куллана. Экспертлар басым ясый: югарыда сурәтләнгән ритм буенча сулау кешенең нерв системасын кыска вакыт эчендә тынычландырырга сәләтле. Шуңа алар әлеге сулыш күнегүен төнлә йокыга китәр өчен генә түгел, бәлки стресстан, күңелгә ятышсыз хисләрдән котылу өчен дә кулланырга киңәш итә.

("Die Presse").

Талпан "химиясе"

Галимнәр кабат әлеге зыянлы канэчкечләрне җентекләп тикшерә башлаган. Эш шунда: талпанның селәгәендә 3 меңләп төрле аксым табылган, алар кешене миокардит кебек рәхимсез йөрәк чиреннән дә сакларга сәләтле икән. Шул ук протеин йөрәк өянәген дә кисәтә. Талпан әлеге матдәне кеше тәненә кадалганда авырту сизелмәсен өчен эшләп чыгара. Элегрәк фармацевтлар талпан селәгәендәге матдәләр нигезендә кан авыруларын нәтиҗәле дәвалау чарасын уйлап тапкан инде. Хәзер йөрәк авыруларын дәвалау препаратларын булдыру планлаштырыла. Британия кардиология ассоциациясеннән профессор Джереми Пирсон әйтүенчә, бу вак бөҗәк һаман яхшылап өйрәнелмәгән әле: аның организмының "химиясе" серләренә төшенү фәнгә күп авырудан уңышлы дәвалау препаратын булдыру мөмкинлеге бирәчәк, шул исәптән хәзер бернинди даруларга да бирешми торган чирләрдән дә.

("Daily Mail").

Исраф итмә!

Дөньядагы һәр илнең бер генә булса да кабатланмас үзенчәлеге бар. Англиядә бу – салкын һәм кайнар су краннарының, кушылмыйча, һәр икесенең аерым торуы. Моның берничә сәбәбе бар. Британия торак фондының күпчелеге XIX гасыр азагы – XX гасыр башында төзелгән. Йортларны су катнаштыргычлар барлыкка килгәнче салганга, баштарак аларның барысында да салкын су краны гына булган. Кайнар судан файдалану мөмкинлеге тугач, икеләтә система булдырып, икенче кран куйганнар. Бөекбританиядә үзәкләштерелгән җылыту системасы юк, шунлыктан һәр фатирда газ колонкасы урнаштырылган. Илдәге закон буенча, бойлердагы кайнар суга салкын су кушу тыела, чөнки андагы цистерна төрле температурадагы су кушылудан чатнарга һәм бөтен системаны сафтан чыгарырга мөмкин. Инглизләр барысы да болай юынырга гадәтләнгән: башта раковина улагын бөке белән томалыйлар, су җыялар да, шунда бит-кулны сабын белән юалар. Аннары чиста су белән чайкамыйлар, сөлгегә генә сөртенәләр. Савыт-сабаны да шулай ук су җыеп юалар, нәтиҗәдә суны исраф итмиләр, акчага да экономия ясыйлар.

("The Times").

Майсыз булмый

Гел майсыз ризык кына кулланучылар организмнарына зур зыян китерә икән. Барселонадагы Европа кардиологлар җәмгыяте конгрессында Канадада үткәрелгән тикшеренү нәтиҗәләре игълан ителгән. Галимнәр, 18 илдә яшәүче 135 мең кешенең туклануын һәм сәламәтлеген күзәтеп, майсыз диета тотучыларның вакытыннан алда үлеп китү куркынычы чирек тапкырга артуын раслаган. Эш шунда: терлек майларыннан баш тарткач, кеше күбрәк икмәк, макарон, дөгене күбрәк куллана башлый. Углеводлар, рафинадланган шикәр, эшкәртелгән ит ризыклары белән тукланырга яратучыларның гомер озынлыгы 28 процентка кыскара. Медиклар исә һаман, кандагы начар холестерин микъдарын арттыра дип, майлы ризыктан баш тартырга өнди. Канадада үткәрелгән тикшеренү авторларыннан берсе Эндрю Менте әйтүенчә, кеше калорияләрнең 35 процентын майлардан алырга тиеш. Компетентлы кардиологлар фикеренчә, халыкны майлы ризык белән куркытудан туктарга вакыт.

